ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 193 (29160) | Җомга | 29 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

2024

Яңа елга ак өметләр белән...

ӨЙЛӘРДӘ ҖАН ҖЫЛЫСЫ ҺӘМ МӘХӘББӘТ ХАКИМЛЕК ИТСЕН!

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ РӨСТӘМ НУРГАЛИ УЛЫ МИҢНЕХАНОВНЫҢ ЯҢА ЕЛ БӘЙРӘМЕ УҢАЕННАН МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле дуслар!

Яраткан бәйрәмебез Яңа елны без гадәттә аеруча шатлыклы хисләр һәм якты өметләр белән каршылыйбыз.

Яңа ел – гаилә бәйрәме, бу исә 2024 елның Россиядә Гаилә елы дип игълан ителүенә символик мәгънә төсмере өсти.

Гаилә – җәмгыятьнең нигезе, менә шуңа күрә дә гаиләдә изге дип саналган һәр нәрсәгә, борынгыдан килгән гореф-гадәтләргә Татарстанда гаять сакчыл мөнәсәбәт күрсәтелә.

Без Татарстан Республикасында яши торган халыкларның мәдәниятен, телен саклауга һәм үстерүгә, рухият нигезләрен, әхлак кагыйдәләрен ныгытуга зур игътибар бирәбез. Төрле милләт һәм дин вәкилләре бер-берсенә тирән хөрмәт белән дус-тату яши, ә республикабыз җәмгыятьнең, гражданнарның бердәмлеге югары булу белән аерылып тора.

Махсус хәрби операция шартларында гражданнарыбызның берләшүе һәм үзара ярдәмләшүе бигрәк тә мөһим.

Илебезнең, гаиләләрнең иминлеген һәм яшь буынның киләчәген яклауны тәэмин итүче Ватанны саклаучыларга олы рәхмәтләремне җиткерәм. Якташларыбыз – чын мәгънәсендә каһарманнар! Барлык сугышчыларыбызга, аларның гаиләләренә, туганнарына һәм якыннарына тиешле ярдәм күрсәтүне дәвам итәчәкбез. Һичшиксез җиңү безнең якта булачак!

Республиканың шефлыкка алган шәһәрләре – Лисичанск һәм Рубежное халкына ихлас йөрәктән ярдәм итүче волонтерлар башкарган хезмәт шулай ук бик әһәмиятле.

Хөрмәтле татарстанлылар!

Узып баручы елны җиңел дип әйтеп булмый, шулай да без сынатмадык.

Куәтле сәнәгать комплексы, күп буын татарстанлыларның хезмәт уңышлары, булдыклылыгы һәм ватанпәрвәрлеге республикага ышанычлы адымнар белән алга барырга мөмкинлек бирә. Россия Президенты Владимир Владимирович Путин тарафыннан башлангыч бирелгән илкүләм проектларны, республика программаларын һәм проектларын үтәү кешеләрнең тормышын яхшыга үзгәртүгә хезмәт итә. Тәмамланып килүче ел йомгаклары тулай төбәк продукты, төзелеш эшләре, ваклап сату һәм инвестицияләр күләмнәре үсүен күрсәтә.

Республиканың алгарышында фәннең һәм күркәм нәтиҗәләр бирә торган яңалыкларның зарурлыгын танып, 2024 ел Татарстанда Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан ителде. Әйдәүче фән һәм мәгариф үзәкләренең эшчәнлеге, талантлы яшь галимнәргә һәм өстенлекле фәнни башлангычларга ярдәм күрсәтү бу өлкәдә казанышларыбызның тагын да артуына китерер һәм илнең технологик яктан бәйсезлегенә ирешү мөмкинлеге бирер дип уйлыйм.

Яңа ел республика өчен колачлы чараларга бай булачак.

Безгә зур ышаныч белдерелде – 2024 елда Казанда БРИКС дәүләтләре башлыкларының очрашуы, «БРИКС уеннары» узачак. Татарстан үзенә хас кунакчыллык белән тарихта беренче «Киләчәк уеннары» мультиспорт турнирын, «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum», Kazan Digital Week – 2024 халыкара форумнарын кабул итәчәк.

Моннан тыш, 2024 елда гаять әһәмиятле сәяси вакыйгалар – Россия Федерациясе Президентын, ә сентябрь аенда җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлау узачак. Татарстанлылар, илебез һәм республикабыз үсеше өчен гражданлык җаваплылыгы тоеп, тавыш бирүдә актив катнашырлар дип ышанам.

Кадерле дуслар!

Безнең алда зур бурычлар тора, киләсе елда аларны хәл итү өчен без тырыш хезмәт куячакбыз һәм бергәләп алгарыш юлыннан баруыбызны дәвам итәчәкбез.

Яңа елда җиңүләр һәм казанышларыбыз күп булсын, өйләребездә җан җылысы, мәхәббәт һәм үзара аңлашу хакимлек итсен!

Сезгә чын күңелдән нык сәламәтлек, иминлек һәм бәхет телим!

Яңа ел бәйрәме мөбарәк булсын!

ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛ ТҮГЕЛ

Татарстан гадәттән тыш хәлләр министры Рафис Хәбибуллин вазыйфадан китүе турында хәбәр итте. Бу хакта ул хезмәттәшләренә Коткаручылар көне уңаеннан узган бәйрәм тантанасында әйтте. Унҗиде елга якын башкарган вазыйфадан китүен министр яшенә бәйләп аңлатты.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча баш идарәсе башлыгының эштән китәчәге турындагы хәбәрләр моңа кадәр үк ишетелсә дә, рәсми мәгълүмат юк иде әле. Имеш-мимешләргә генерал-лейтенант Рафис Хәбибуллин үзе нокта куйды.

– Әлеге вазыйфадан китүем турында рәсми рәвештә белдерәм. Бу урында, биш айны исәпкә алмаганда, 17 ел эшләдем. Һәр кешенең тормышында нәтиҗә ясау һәм алдагы язмышы турында тиешле карар кабул итәргә кирәклеген искәртү чоры җитә, – диде ул хезмәттәшләре алдында чыгыш ясаганда.

Китүен ул дәүләт вазыйфасын башкаруда чик яшенә җитүе белән аңлатты. «Баш идарә һәм министрлык бусагасын атлап кергәндә, гражданнар оборонасы өлкәсендә тиешле белемем юк иде диярлек. Моңа да карамастан, без бергәләп төбәк идарәсен ил күләмендә әйдәп баручылар рәтенә чыгара алдык. Бик күп сулар акты. Без чын мәгънәсендә галәм масштабындагы вакыйгалар шаһитлары һәм катнашучылары булдык. Теләсә кайсы авыр хәлдән җиңүчеләр булып чыктык», – диде Рафис Хәбибуллин. Ул хезмәттәшләрен ышанычлы иптәшләре дип атады һәм рәхмәт әйтте.

Рафис Хәбибуллин урынына кем киләсе әлегә билгеле түгел.

ТАТАРСТАН ӨЧЕН 2023 ЕЛ – САННАРДА

Икътисадый уңышлар

- Тулай төбәк продукты **4 трлн сум (үсеш – 102,8%)**
- Җибәрелгән продукция күләме **4,5 трлн сум**
- Сәнәгать җитештерүе индексы (ИПП) **102,4%**
- Төзелгән һәм төзекләндерелгән **4 мең объект**
- Кулланышка тапшырылган торак **3 млн кв. метрдан** артык
- Ашлык уңышы **3,6 млн тонна**
- Сөт **2,1 млн тонна** (икенче ел рәттән)
- Ислам хезмәттәшлеге оешмасы илләре белән товар әйләнеше **4 млрд 185 млн доллар**
- Идел буе федераль округының тышкы сәүдә күрсәткечендә Татарстан өлеше **30%**

Социаль тармак

Уртача хезмәт хакы >> **58902 сум**

2023 елда өйләнешүчеләр	**22 мең**
2023 елда туучылар	**33 мең**
Спорт белән шөгыльләнүчеләр	**61%**
Үзмәшгульләр	**292500**

Юбилейлар

Дары заводы	235 ел
«Позис»	125 ел
«Вакууммаш»	80 ел
Электромеханика заводы	75 ел
«Казаноргсинтез»	65 ел
«Ремдизель»	45 ел
ТАИФ-НК	25 ел
Нефтьне эшкәртә башлауга	80 ел
«Ватаным Татарстан» газетасына	105 ел


«Татар-информ»

НИЧЕК УЗДЫ?

Венера ГАЛИЕВА,
үзмәшгуль (Әлки):
– Ел сизелмичә дә узып китте. 21 декабрь көнне гаиләкоруыбызга 30 ел тулды. Әле генә тормыш башлаган идек. «Кая чаба икән бу гомер?» – дип аптырап утырам. Буй җиткән балаларга карыйм да, оныкларны сөям дә шөкер итеп куям. Төп йортта каенанам, улыбыз, киленебез белән бергә яшибез. Ирем оста итеп сыннар ясый. Бу арада эше каты. Әле бер оешма ишегалдын бизи, әле икенчесен. Яңа елны бик көтәм. Гыйнвар башында туган көнем. Инде киленем белән кунаклар исемлеген дә әзерләдек. Баянчы абыебыз бар, сүзгә оста туганым да бар. Бергәләп матур итеп уздырып җибәрербез дип торам.

Рафаил ХӘКИМОВ,
машина йөртүче (Мамадыш):
– Бу арада кар явып, эш ясады. Урамнан да чыга алмыйча яттык. Әле ярый юлларны гел чистартып торалар. Отпуск алган идем, эшкә барасы булмагач, рәхәт. Әмма хатынымны, балаларымны мәктәпкә йөртәсе бар. Кыш көне ял алганым юк иде, бер дә кирәкле әйбер түгел икән. Яңа елны көтмим. Янәсе, бокал чәкештереп, теләк телисең дә, яңа ел килә. Ятып йокласаң да, таң ата инде ул. Бер генә теләк: илләр тынычлансын иде, дим. Күрше егетебез – махсус хәрби операциядә. Әле менә аңа кирәк-яраклар барлап йөрим.

Гөлшат ШӘЙМӘРДАНОВА,
пешекче (Кама Тамагы):
– Елның узганын сизми дә калдым. Быел язмыш мине төрлечә сынады. Февраль аенда ирем үлеп китте. Ашказаным авырта, дип йөри иде. Йокыдан тормады. Табиблар, йөрәк, диде. Бик еладым. Гомеремдә бер түләү түләмәгән, ризык та сатып ала белмәгән хатын идем. Авыр чакта улларым ярдәм итте. Әле менә кызым сөендерде. Икенче бәбиләрен көтәләр икән. Рифатымның онык сөеп калганына да шатланам. Ә бит кызыбызны бер дә кияүгә бирәсе килмәгән иде. Яшь дип, каршы килеп маташтык. Шөкер, кияү белән бик матур яшәп яталар. Олы оныгыма – 4 яшь. Анысы кыз иде, икенчесен малай дигәннәр. Тормыш шулай инде. Кайгы да килә, шатлыгы да сөендерә. Яңа елда һәр кешегә ныклы сәламәтлек, тигез гомер, гаиләләрдә тынычлык телим.

Сәлимә СӘЕТОВА,
кибетче (Ютазы):
– Гаиләбездә зур сөенеч әле. Беркемгә дә сиздермичә, махсус хәрби операциядән киявебез кайтып керде. Шатлыктан елап беттек. Киткәненә 9 ай иде. Ул балаларын күрсәгез! Кыш бабайдан бүләк сорамаганнар быел, «Әти кайтсын!» – дип хат язган булганнар. Шулкадәр ышандылар инде. Әтиләре яныннан китмиләр дә. Бөтен туганнар җыелышты. Рәхәт мизгелләр әле бездә. Үземнең улым да – махсус хәрби операциядә. Ул ялга кайтып китте инде. Хәзер аларның бөтенләй кайтуын көтәбез. Тормыш дәвам итә. Ике сыерым бозаулады. Берсе игез үгезләр китерде. Сарай тулы кошкорт. Көзен генә үрдәгем балалар чыгарган иде. Шуларны үстерәм. Этебез чыгып югалгач, яңа көчек алдык. Мәш килеп ятабыз. Һәр туган көнгә рәхмәт укып, гаиләмдәгеләргә исәнлек сорап яшим.

Нурзия ХӘБИБУЛЛИНА, кондуктор (Чаллы):
– Узып баручы елга рәхмәт. Эшем җиңел булмаса да, матди хәлемне яхшырттым. Авырган кеше өчен дә эшкә чыктым, ялга китүчеләрне дә алыштырдым. Үзем бик арысам да, бурычларымнан котылгач, бик рәхәт. Ирем белән бергә алган кредит иде ул. Ул ике ел элек кинәт кенә вафат булды. Хәсрәтемне эш белән бастым. Әле менә шушы көннәрдә кызыбызны сорарга килделәр. Киләсе елыбыз күңелле мәшәкатьле булачак. Ял итеп ятып булмый монда. Исән-сау үз аягында йөреп эшләргә язсын.

Габбас ГАЛӘВЕТДИНОВ,
янгын сүндерү станциясе хезмәткәре (Биектау):
– Минем өчен гомеремнең һәр елы кадерле. Быел 65 яшемне тутырдым. Хатыным вафат булгач, берсеннән-берсе кечкенә ике кызым белән калдым. Ул чакларда ярый әнием ярдәм итте. Инде хәзер балаларым буй җитте. Бер кызым кияүдә. Икенче оныгым туды. Шуларга карап сөенеп яшим. «Әти» дип өзелеп торалар. Тик яткан юк. Әле менә урамнарны бизәргә чыктым. Күңелдә Яңа ел кәефе бар инде ул. Әле бит эшләп тә йөрим. Эшемне бик яратам. Шөкер, быел урманнарда янгын булмады. Ут чыгып куркытмады. Безнең әзерлек көчле. Без эшләгәндә, ут чыкмас, дип шаяртам да инде мин. Эшемне дә күрәләр. «ТАССР-ның 100 еллыгына» дигән медаль бирәчәкләр. Татарстан Рәисе имзалаган инде.

Лилия ӘХМӘТШАКИРОВА,
мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе (Яшел Үзән районының Олы Яке авылы):
– Ел бик уңышлы булды. Күп эшләсәк тә, зарланырлык булмады. Кайда гына йөрмәдек, нинди генә бәйгеләрдә катнашмадык. Төрле җирләрдә чыгыш ясадык. Шөкер, эшләгәнне күреп, җитәкчеләр бәяләде дә. Гаиләм өчен 2023 ел бик сөенечле хәлләргә бай булды. Әби булдым. Беренче оныгым Зифа туды. Киләсе елда тагын бер улым өйләнәм дип тора. Зур эшләребез бар. Балаларны башлы-күзле итү – һәр ата-ананың бурычы инде ул. Без барысын да эшлибез, үзләре корган ояларын саклап, матур итеп яшәсеннәр иде. Безгә шуннан зур бүләк булмас.

Язучы фикере

Битлек

Бер мәлне Яңа ел бәйрәме чорында битлек киеп йөрү модага кереп китте. Аю, бүре, куян, төлке… Тагын әллә кемнәр. Кая бакма шулар. Без – өч дус, өч студент – бүтәннәрдән аерылыбрак торырлык битлек табып булмасмы дип, базарга киттек. Табып булмады. Шулай да базардан чыгышлый бер көньяк кешесе килеп, тавык кетәгә кебек кенә бүлмәсенә алып керде. Һәм битлекләр тартып чыгарды. Без «Аһ!» иттек. Мондыйны бары тик чит илдән килгән ужастикларда гына күргән бар иде. Берсе әҗәл битлеге инде. Икенчесе шүрәле бугай. Өченчесе шайтан булырга тиеш, хәтта тырпаеп торган мөгезе дә бар. Җилемнән ясалган, башыңа киеп куймалы. Кыйммәт.

– Алыгыз, ал, – диде сатучы, безнең икеләнеп торуны күреп. – Моны киеп чыксагыз, бөтен матур кыз сезнеке була.

Йөргән кызыбыз булгач, Илгиз белән минем бик ис китмәде, ә Айдар дигәнебезнең күзләре ялтырап куйды.

– Әйдә, алабыз! – Без нидер уйлап өлгергәнче, ул инде кесәсенә тыгылды. – Үзем түлим.

– Кит әле, моны кисәң, фәлән ел яшәгән хатының куркып качар, – дип кул селтәде Илгиз. – Бөтен матур кыз, имеш…

Шулай да без алырга булдык.

Ул вакытта әле мондый битлекләр беркемдә дә юк иде. Урам буйлап шуны киеп йөрсәң, коты алынган берәр адәм бәреп үтерергә дә мөмкин. Ә менә тулай тораклар алдындагы чыршы янына киеп чыгарга була. Без шулай итәргә булдык. Тик мин кием чыга алмадым. Бүлмәдәш егетләрнең берсе: «Коридордан гына урап киләм, биреп тор инде?» – дип бик ялынып сорап алды да суга төшкәндәй югалды. Ә Илгиз белән Айдар…

Илгиз тулай торак алдына чыккан да, ышыграк урынга басып, Айдар белән мине көтеп тора икән. Кәефе күтәренке, бәйрәмчә инде. Яныннан бер кыз үтеп бара моның. Матур кыз инде шундый. Егет түземи, шаяртып алырга була:

– Бәйрәм белән, матурым! – дип ышык урыныннан чыга ул. – Әниегезгә кияү кирә…

Кыз елмаеп борыла, нидер әйтергә тели… Катып кала… Һәм яман тавыш белән кычкырып җибәрә дә коты алынып йөгерергә тотына. Үзенең битлектә икәнен оныткан Илгиз моның артыннан чаба:

– Нәрсә булды? Туктагыз әле.

Кыз кычкыра-кычкыра җиппәрә генә… Ә Илгиз аның артыннан…

Нәкъ шул вакытта тулай торактан Айдар килеп чыга. Кәефе бәйрәмчә моның да. Тик ярдәм сорап кычкырган хатын-кыз тавышы ишетеп сагаеп кала һәм шунда ташлана. Күрә инде: караңгы сукмак буйлап бер кыз йөгерә, аны кемдер куа. Айдар, җитез дә, көчле дә егет, колачын җәеп, кызның алдына төшә дә кочаклап ала.

– Тынычланыгыз, – дип юата ул. – Куркыныч юк. Сез минем янда.

Күзенә ак-кара күренми йөгергән җиреннән яклаучыга юлыккан кыз башын аның күкрәгенә терәп сулкылдый башлый, бераздан тынычлангандай булып күтәрелеп карый да… Үзенең шүрәле куенында икәнен күреп тагын кычкырып җибәрә. Тыпырчына башлый. Ул арада Илгиз килеп җитә һәм тынычландырырга тотына:

– Борчылмагыз, зинһар…

Кыз тынычланмый. Өнсез калып, әле берсенә, әле икенчесенә карап тора да һушсыз егыла.

Егетләр дә бер-берсенә карашып бераз торгач, эшнең нидәлеген төшенәләр һәм битлекләрен салып, агач төбенә ыргыталар. Кызны һушына китерергә тырышалар. Ахыр чиктә, Айдар, сак кына күтәреп, аны үзләренең бүлмәсенә алып кереп китә…

Битлек юллап этаждан этажга йөреп, мин бу тамашага өлгерә алмый калдым. Табылмады. Тик бераздан бүлмәдәш аксый-туксый үзе килеп чыкты. Ирене ярылган, күз төбе күгәргән иде. Күреп өйрәнелгән нәрсә булмагач, куркудан кыйнаганнардыр инде.

Нәкъ бер елдан соң Айдар теге кызга өйләнде. Бергә яшәүләренә – 33 ел. Яңа елда могҗизалар булмый дип кем әйтә анда?

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Могҗиза

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Беркөнне оныгым Кәрим: «Дәү әти, син Кыш бабайның барлыгына ышанасыңмы?» – ди.

– Ышанам, улым.

– Ә мин юк. Хәтерлисеңме, кечкенә чакта мине Яңа ел белән котларга Кыш бабай чакырган идегез. Ә ул чын Кыш бабай түгел, әтинең дусты булып чыкты.

Кара әле моны, «мин кечкенә чакта...» дип сөйләнеп утырган була, үзенә ун яшь тә юк бит әле.

– Улым, Кыш бабай чакырган елны синә ничә яшь иде соң?

– Дүрт. Мин бөтенесен дә хәтерлим. Дәү әти, өлкәннәр ни өчен гел алдый икән ул? Миңа син дә: «Балаларны кәбестә арасыннан табып алалар», – дип сөйли идең. Балаларның каян килүен беләм бит мин.

Үзе сөйләнә, үзе, миңа карап, хәйләкәр генә елмая Кәрим. Бер уйлаганда, балаларның кәбестә арасында табылуына кечкенә чакта без дә ышанмый идек, тик сөйләп кенә йөрмәдек.

Кыш бабайга да бик ышанмадык, чөнки Кыш бабай булып ел саен бер үк укытучы киенә иде. Аның безгә – чыршы тирәсендә җыелган балаларга нәрсәләр әйтәсен дә ятлап бетергән идек. Тик күңел могҗиза сорады. Шуңа күрә: «Кыш бабай, Кыш бабай!» – дип кычкыра-кычкыра, үзебезнең бәйрәмгә чакыра идек. Инде Яңа ел күчтәнәчләре тутырган капчыгын асып, безнең янга килеп керсә, дөньябызны онытып кул чабу, аңа багышлап җыр башкару бәйрәмнең иң югары ноктасы саналды.

Кыш бабай да үз җырын башкарды. «Мин – Кыш бабай, Кар бабай, бик еракларлардан килдем...» Кайвакыт җырының сүзләрен оныта иде ул. Кыш бабайны күңелсез хәлдә калдырасы килми бит инде. Шуңа күрә беребездән-беребез уздырып, җырга кушыла идек: «Ракетага утырып, Ай тирәсендә йөрдем».

Без Кыш бабайның айга менүенә дә ышанырга теләдек һәм бу ышану хисе күңелгә әйтеп бетерә алмаслык рәхәтлек бирә иде, без үзебезне могҗизалар дөньясында кебек хис иттек.

Әле бүген дә Кыш бабайның – 1699 елда Петр патша, ә Кар кызының 1937 елда Сталин фәрманы белән дөньяга килүләре һәм Яңа ел бәйрәмендә катнаша башлаулары турында уйлап та карамыйбыз. Әйтерсең лә алар гомер буе булган.

Без Яңа ел күчтәнәчләрен нәкъ Кыш бабай алып килүенә дә ышандык. Тик миңа бу хәтле балага өләшерлек күчтәнәч Кыш бабайның кеп-кечкенә капчыгына ничек сыеп бетә икән дип тә шикләнә идек. Кыш бабай моны үзе дә сиздe кебек. Сизмәсә, бергә уйнап-җырлап чыршы тирәли әйләнеп йөреп арыгач: «Балалар, хәзергә сезнең белән саубуллашам, минем әле тагы берничә бәйрәмгә барасым бар. Ә күчтәнәчләрне сезгә класс җитәкчеләрегез тапшырыр, яме», – димәс иде. Һәм без нишлибез? Әлбәттә инде, күчтәнәч алу өчен бәйрәмнең тәмамлануын көтәбез. И-и, гөнаһсыз балачак диген! Безнең буын һәр Яңа елны могҗиза дип кабул итте. Еллар алышынганда, могҗизаларга ышанып, өметләнеп, теләкләр теләү кеше күңелендә бүген дә яши. Галимнәр әйтүенчә, моның ике сәбәбе бар. Берсе – Аллага, ниндидер илаһи көчкә ышану. Андыйлар Җир шарындагы халыкның 85 процентын тәшкил итә икән. Икенче сәбәп – кешенең үз көченә ышанып бетмәве. Мондый халәттә адәм баласы, әлбәттә инде, могҗиза көтә. Бер уйлаганда, еллар алышуы – үзе үк зур могҗиза. Кешеләр үз гомеренең яңа исәбен ачалар. Ике исәп арасы – яшәешебезнең инде үтелгән кадерле мизгелләре. Елларны санап бару – үзе бер бәхет, димәк, тормыш дәвам итә, дигән үзе. Вакыт галиҗәнаплары туктап калса нишләрсең, Алла сакласын! Ә Яңа елда үзебезгә, якыннарыбызга, дус-ишләргә матур теләкләр тели-тели, без яңа шатлыкларга омтылабыз, бәхетле мизгелләрне якынайбыз кебек. Шулай булсын иде!

КАНАТЛАР САЛЫНМАСЫН

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Без ел саен үткән елга йомгак ясап, алдагы елга вакыйгалар үсешенең төп сызыкларын чамаларга тырышып карыйбыз. Алдан ук ассызыклап куйыйк: киләчәктәниләр буласын әйтергә җыенмыйбыз, чөнки белмибез.

Үткән елларда алдагы календарь елга фаразлар язганда, без хәлләрнең елдан-ел катлауланасын, авырлыкларның артасын, сынауларның көчәячәген әйттек. Бу безнең сүзләр генә түгел, дөньякүләм лидерлар теленнән андый фаразлар бик еш яңгырый. Әйтик, Путин 2022 елда Валдайда чыгыш ясаганда ук: «...положение дел чревато цепью конфликтов, которые будут представлять угрозу для всего человечества», – дигән һәм кешелек дөньясының Икенче бөтендөнья сугышыннан соң иң куркыныч чорга аяк басуын әйткән иде. Байденга сүз бирсәк, аның теленнән алдагы дүрт-биш елның кешелек дөньясы үсешен хәл итәчәк еллар булуын әйтәчәк. Казахстанның беренче Президенты Назарбаев быелның 12 декабрендә генә: «Без беркайчан да булмаганча атом-төш катастрофасына якын торабыз», – диде. Автор укучыларны юата ала: глобаль атом-төш һәлакәте булмаячак. Тактик атом коралының шартлавы мөмкин, әлбәттә. Ләкин андый шартлау берничә квадрат километр җирдә генә зыян сала, планетадагы тормышны куркыныч астына куймый. Без сиончы гыйбриләр төзегән «Израиль» дип аталган ясалма берләшмәнең тарихи аренадан юкка чыгу алдында торуын күрәбез. Менә шул дәүләтнең хәрби доктринасында, юкка чыгарлу куркынычы туганда, атом-төш коралын куллану мөмкинлеге каралган. Россия – Украина конфликтына бәйле рәвештә андый янаулар булды, ләкин күрәбез: конфликт – торгынлык стадиясендә, стратегик тупикта. Тупиктан бары тик сөйләшүләр юлы белән генә чыгып була. Кремльдән Көнбатышка таба соңгы көннәрдә генә сөйләшүләргә әзер булу турында берничә сигнал җибәрелде.

2023 елга фаразлар язганда без ике юнәлешкә игътибар юнәлтергә тырышканбыз: «Бар ислам дөньясында тектоник плитәләрнең көчле хәрәкәте көтелә... Ислам дөньясында үзгәрешләр бөтен дөньяга нык тәэсир итәчәк», – дигәнбез. 7 октябрьдә Фәләстыйн җирләрендә башланып киткән моңарчы күрелмәгән зур канкоеш мөселман дөньясында гына түгел, бөтен планетада зур урам хәрәкәтләре башланып китүгә этәргеч бирде. Европада да, Америкада да кешеләр аңында зур үзгәрешләр бара. Бу вектор үзенең үсешен дәвам итәчәк, исән булсак, без Якын Көнчыгышның зур тетрәнүләр чорына аяк басуын күрербез әле. Әлегә вакыйгалар үсешенең зур траекториясенә Йәмән гыйсъянчылары гына тартып кертелде һәм алар, Көнбатыш коалиция Йәмәнгә һөҗүм итсә, бар кешелек дөньясын таш гасырга кайтарырга вәгъдә бирә. Ул вәгъдә буш куык кына түгел. Моны АКШ төзегән «Чәчәк ату сакчылары» дип аталган коалициянең һөҗүмгә күчәсе урынга бик тиз таркалуыннан да аңлап була. Испания, Франция, Италия кебек Европа илләре үз хәрби корабларын американнарга ярдәмгә җибәрүдән баш тарттылар. Башта риза иделәр, йәмәнлеләрнең янавыннан соң, тәртәләр кире борылды. 26 километр гына киңлектәге Бәб әль-Мәндеб бугазы планетаның бик нечкә урыны булып чыкты. Ул – сәүдә кораблары өчен генә түгел, Җир шарының технологик потенциалы өчен дә әһәмиятле төбәк һәм йәмәнлеләр безнең барыбызны да интернеттан мәхрүм итү куәтенә ия. Хәзер бар сәнәгатьнең, хәтта атом-төш станцияләренең дә бөтендөнья челтәре аша идарә ителүен исәпкә алганда, атом сугышыннан башка да таш гасырга әйләнеп кайту бик мөмкин эш булуын аңларга була.

2023 елга фаразлаган икенче проблеманы «2023 ел глобаль рецессиянең авыр сулышы белән тарихка кереп калыр», – дип билгеләгәнбез. Рецессия Европада башланды, Америкада аны көтәләр... Африкада инде

«Татар-информ»

өченче ил – Эфиопия бурычларын түләүдән туктады, ягъни дефолт бусагасын атлады. Дефолтлар парады 2024 елда көчәер дип уйлыйбыз. Россиядә икътисадый кыенлыклар «йомырка кризисы» буларак аваз бирде. Сайлау алды чоры булуга карамастан, азык-төлек бәяләренең ел башында ук 22 процентка кадәр күтәреләчәген вәгъдә итәләр. Андый вәгъдәләр тормышка ашучан.

2023 елга әйләнеп карасак, без аның табигый бәла-казаларның масштаблы үсешеннән торуын күрербез. Төркиядә һәм Сүриядә тарихта тиңе булмаган зур җир тетрәү... Әфганстанда күп үлемнәргә китергән шундый ук фаҗига күптән түгел генә булды. Соңгы көннәрдәге Кытай җир тетрәве шулай ук корбанлы. Статистика тектоник плитәләрнең хәрәкәте артуын раслый. Хәрби конфликтлар саны арта. Бүген дөньяда 183 кораллы конфликт бара дип раслыйлар. Бу – тарихи рекордлы күрсәткеч.

Җир шарының гаделсезлек һәм золым белән тулуы – ахырзаман эволюциясе, көтелә торган һәм алдан әйтелгән нәрсә. Вакыйгалар шуны раслап үсә. Әмма спиральнең шул рәвешле бөтерелүе мәңгелек түгел. Зур системаның җимерелеп, яңа система туу мизгеле һәрвакыт шулай авыр һәм мәшәкатьле була. Иң гади математик исәп тә процент капиталына корылган икътисадның җимереләчәген күрсәтә. «Франция бурычы, салымнарның гадәттән тыш зур булуына карамастан, контрольдән чыгып бара», – дигән хәбәр укыйбыз банк аңалыкларыннан. Бер Франция генә булса икән, барлык илләр шул эздән һәлакәткә таба атлый. Глобаль конфликтларны шул тудыра да инде. Россия риба системасына соңга калыбрак килеп кушылды, шуңа күрә бездә әлегә аның нәтиҗәләре соңга калыбрак сизелә. Әмма Үзәк банк: «Россия икътисады кызган моторны хәтерләтә», – дип бәяләде инде.

Без социалистик система җимерелеп, базар икътисадына күчкән елларны яхшы хәтерлибез. Санаулы көннәр эчендә гомер буе җыйган байлыкларның юкка чыгуы, эшсезлек һәм акчасызлык, гиперинфляция... Тәҗрибә шуны күрсәтә: кемнәр канатларын салындыра, шулар һәлак була. Шуңа күрә төшенкелекне үзегезнең рухи дөньягыздан ерак куыгыз. Адәм баласының бүгенге хәле бернигә дә карамастан кичәгегә караганда яхшырак булырга тиеш. Юк, сүз матди хәлнең яхшыруы хакында бармый, рухи яктан үсеш һәм ныгу хакында әйтәбез. Көннән-көн күңелең чистара икән, барлык начарлыкларның да ахыры яхшы тәгәлләнә. Авырлыклар безгә чистарыну өчен бирелә дә инде.

Эльвира
ВӘЛИЕВА

КУЯННЫ ОЗАТКАНДА

2023 ЕЛ НИЛӘР БЕЛӘН ИСТӘ КАЛДЫ?

116.ru

Бу елның санаулы сәгатьләре калып бара. 2023 елның борчулары да, шатлыклары да шактый булды. Ул ниләр белән истә калды? Узып баручы елга йомгак ясап, Татарстан һәм ил күләмендә игътибарны җәлеп иткән төп вакыйгаларны барладык.

Яңа атама

Республикада «Татарстан Рәисе» атамасы гамәлгә керде. Татарстан Конституциясенә кертелгән үзгәрешләр нигезендә, без республика башлыгы Рөстәм Миңнехановка әнә шулай дип дәшә башладык. Билгеле булганча, аңа кадәр Татарстанда Президент атамасын үзгәртү турында закон кабул ителеп, анда үзгәртү өчен күчеш чоры билгеләнгән иде. Ягъни республика башлыгының яңа атамасы яңа сайланган җитәкчегә генә кагылачак, диделәр. Тик депутатлар әлеге җитди мәсьәлә буенча тагын бер кат сөйләшкәннән-киңәшкәннән соң, күчеш чорыннан баш тартырга булдылар. Утырышта кабул ителгән закон проекты 2023 елның 6 февралендә үз көченә керде. Шул көннән без Рәисле булдык.

Ел шәхесе

Якташыбыз, өлкән лейтенант, танк ротасы командиры Рәсим Баксиковка махсус хәрби операциядә күрсәткән батырлыгы, кыюлыгы һәм фидакарьлеге өчен Россия Герое исеме бирелде. Дәрәҗәле бүләкне аңа Россия Президенты Владимир Путин тапшырды. Рәсим Баксиков – Алексеевск районының Биләр авылыннан. Яу кырында якташыбыз җитәкчелегендәге данлыклы «Алеша» танк экипажы берүзе дошманның бронетехника колоннасын тар-мар итә. Бәрелеш барышында дошман сигез хәрби техникасын югалта. Махсус хәрби операция башлангач, үзе теләп, Ватанны сакларга киткән Рәсим Баксиков бик күп ир-егетләр өчен үрнәк кешегә әверелде. Ә андыйлар аз түгел. Аларның батырлыгы турында хәбәрләрне еш ишетәбез. 2022 елның февралендә махсус хәрби операция башланганнан бирле Татарстаннан 11 хәрби Россия Герое исеменә лаек булды, 1 меңнән артык солдат төрле орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, республика якташларыбыз яу сызыгында уңышка ирешсен, ә аларның гаиләләренә тиешле матди һәм рухи ярдәм күрсәтелсен өчен, хәлдән килгәнне эшли. Узып баручы елда Татарстан башкарган төп эшләрнең берсе әнә шул булды.

Милләт көче

Быелның маенда Курган өлкәсендә көчле янгын чыгу аркасында тулысынча диярлек янып көлгә әйләнгән Йолдыз (Эчкен) авылын торгызуда бөтен татар дөньясы катнашты. Авылда 228 йорт янды. Татарстан беренчеләрдән булып милләттәшләребезгә ярдәм кулы сузды. Төзелеш материаллары белән беррәттән, республикада гуманитар ярдәм җибәрү эше дә оештырылды. Беренче «өй туйлары» да узды инде. Хәзер авылда йөз яңа йорт төзелә. Аларның 40ы яңа елга кадәр үк тапшырылачак. Тагын 36сы гыйнварда әзер булачак. Калганнарын язга өлгертергә ниятлиләр. «Без татар халкына чиксез рәхмәтле. Өйләргә – суыткыч, укучыларга – сәпид, укытучыларга ноутбукка кадәр алып бирделәр», – ди Йолдызда яшәүче Гөлсинә Байтирәкова.

tatar-inform.ru

Процентлы баю

Быел Россия Үзәк банкы төп ставканы 7,5тән 16 процентка кадәр күтәрде. Ягъни бер ел эчендә аны ике тапкырдан да күбрәккә арттырдылар. Бу шул исәптән халык арасында кредитлар алу хисабына акча тотуны киметү өчен дә эшләнде. Соңгы мәгълүматларга караганда, илдә яшәүчеләрнең кредитлар буенча 35 триллион сумга якын бурычы бар. Аңлашыла ки, төп ставка артыннан куллану кредитлары, ипотека ставкалары да артты. Хәзер банклар куллану кредитын, мәсәлән, 16–18 проценттан бирә. Белгечләр әйтүенчә, төп ставка арту киләсе ел башында да дәвам итәчәк. Үзәк банкның киләсе утырышы 2024 елның февраленә билгеләнгән. Анда төп ставка тагын 1–2 процентка артырга мөмкин.

Эссе сынау

Узып баручы ел табигать кыланмышлары белән дә истә калачак. Бигрәк тә җир кешесендә. Бу җәйдә көннәр артык коры һәм эссе тору сәбәпле, Татарстанда гадәттән тыш хәл режимы кертелде. Май, июнь айларындагы эсседә синоптиклар кат-кат рекорд яңартты. Ә авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләргә исә югалтуларны санайсы гына калды. Корылык аркасында республикада ашлык җитештерү 30 проценттан да күбрәккә кимегән, диләр Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында. «Ел үзенчәлекле, коры булды. Яз иртә килде һәм чәчүгә керештек. Шуннан соң берничә көн салкын булды. 50 мең гектарга якын көзге культураны югалттык», – диде министр Марат Җәббаров.

Киләчәккә юл

М12 автомобиль юлы ачылды. Мәскәү – Казан түләүле трассасы тарихка иң тиз төзелгән һәм иң заманча юл буларак кереп калачак. Аны алдан фаразлаганнан ярты елга иртәрәк кулланышка тапшырдылар. М12 «Көнчыгыш» югары тизлекле трассасы илнең 5 төбәге – Мәскәү, Владимир, Түбән Новгород өлкәләре, Татарстан һәм Чувашия республикаларын тоташтыра. Ул Татарстанның Кайбыч, Апас, Югары Ослан, Лаеш һәм Питрәч районнары аша уза. Юлны Екатеринбург, Чиләбе һәм Төмәнгә кадәр озайту турында да карар кабул ителде. Алга таба М12не Иркутск һәм Владивостокка кадәр җиткерү, Казахстан, Монголия һәм Кытайга чыгу да күздә тотыла. Юл төзелешенә инвестицияләрнең гомуми финанс нәтиҗәлелеге 1,8 триллион сум күләмендә бәяләнә.

russianhighways.ru

Алтынга тиң йомырка

Быел илдә тавык йомыркасы 50 проценттан да күбрәккә кыйммәтләнде. Бәяләр күзгә кергәч югары «сикерде». Алтынга тиң йомырка өчен Россия Президенты Владимир Путинга халык алдында гафу үтенергә туры килде хәтта. Әлеге хәл Хөкүмәт эшендәге төгәлсезлек аркасында килеп чыкты, диде ул «туры элемтә» барышында. Бәяләр киләсе ел башында төшә башлаячак, дип көтелә. Йомырканы Төркия, Азәрбайҗан, Иран кебек чит илләрдән кайтара башладылар. Быелның 11 аенда республикада 1 миллиард 453 миллион данә йомырка җитештерелгән. Алдагы елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, бу 33,6 миллион данәгә күбрәк. Әмма аңа ихтыяҗ да зур. Шушы арада гына Казанда узган ярминкәләрнең берсендә ике сәгать эчендә 200 мең данәдән артык йомырка сатып алганнар әнә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Зөһрә
САДЫЙКОВА

БӘРӘКӘТ КӨТӘ КҮҢЕЛ

ҖИР КЕШЕСЕН НӘРСӘ СӨЕНДЕРГӘН ҺӘМ КӨЕНДЕРГӘН?

Авыл хуҗалыгы тармагында елның җиңел килгәне юк, тик игенчеләр дә, терлекчеләр дә бернигә карамастан, куелган бурычларны намус белән башкара. Быел да нәрсәләрдер аларны күбрәк сөендерде, ә кайсыларыдыр аеруча көендерде. Шулай итеп, елга йомгакны хезмәт кешеләре белән бергәләп ясадык.

Ленар Абдуллин

Нурислам САБИРҖАНОВ

Вазыйфасы һәм эш урыны: Балтач районының «Бөрбаш» хуҗалыгында комбайнчы.

:: Быел авыл хуҗалыгы тармагында һәм шәхси тормышыгызда сезне нәрсә сөендерде?

– Мин авыл хуҗалыгында 1984 елның җәеннән бирле эшлим. Соңгы елларда тармакта хезмәт хакы ел да артып бара. Шуңа сөенәм. Быел хуҗалыгыбыз мул уңыш җыеп алды: гектарыннан 38 центнер. Үзем «Ел комбайнчысы» булып танылдым, 50 мең сум күләмендә премия алдым. Узган ел – 50 мең, 2021 елда – 25 мең, 2020 елда 100 мең сум премия бирделәр. «Атказанган механизатор» дигән мактаулы исемем булгач, хезмәт хакына ай саен 20 процент акча өстәлеп бара. Урыпҗыю вакытында 300 мең сум акча алганда, анысы бигрәк тә яхшы сизелә. Болардан тыш, хуҗалык һәм район, эшләгәнеңә карап, өстәмә акчасын, ашлыгын һәм бозавын бирә. Уртача хезмәт хакы аена 68 мең сум чыга минем. Ничек сөенмисең шуңа? Яшьләр дә 40 мең сумнан да ким алмый. Миңа – 57 яшь, ләкин саулык булганда бер дә туктыйсы килми әле. Эшемне бик яратам. Гаиләбездә дә бик сөенечле вакыйга булды: улыбыз өйләнде.

:: Нәрсә көендерде?

– Авыл тулы эшсезләр, тик колхозда эшләргә кеше юк. Иң нык кәефне кырганы шул. Механизаторлар елдан-ел кими, өлкәнәя.

:: Киләсе елдан ни көтәсез?

– Тынычлык, саулык, мул уңыш көтәм. Колхозның эшләре шулай ук матур барсын иде. Җитәкчебез исән-сау булсын, ул хуҗалыкны бик тырышып алып бара.

Гөлчәчәк СӘЛАХИЕВА

Вазыйфасы һәм эш урыны: «Кызыл Шәрык Агро» җәмгыятенең «Әҗәл» комплексында бозау караучы.

:: Быел авыл хуҗалыгы тармагында һәм шәхси тормышыгызда сезне нәрсә сөендерде?

– Минем өчен бик уңышлы ел булды. «Дочка» кушаматлы сыерны башта республикада узган «Бөтенроссия кыр көне – 2023»кә әзерләдем, анда җиңгәч, Мәскәүдә узган «Алтын көз» XXV Россия агросәнәгате күргәзмәсендә чыгыш ясап, алтын медаль белән кайттык. Дөнья күреп, әллә никадәрле кешеләр белән танышып, аралашып кайттым. Эшемдә болай күтәрелгәнем юк иде әле. Бик шатмын моңа. Моннан тыш, кечкенә кызымны кияүгә бирдек. Анысы да – зур, сөенечле вакыйга.

:: Нәрсә көендерде?

– Дөньяның тыныч булмавы күңелемне бик нык борчый.

:: Киләсе елдан ни көтәсез?

– Тынычлык, матур хәбәрләр, тигезлек, саулык көтәм.

Алмаз САБИРОВ

Вазыйфасы һәм эш урыны: Чистай районының Кызыл Ялан авылында яшелчәчелек белән шөгыльләнүче фермер.

:: Быел авыл хуҗалыгы тармагында һәм шәхси тормышыгызда сезне нәрсә сөендерде?

– Яшелчәчелек тармагы өчен быел бик уңышлы булды. Уңыш күләме мулдан булмаса да, бәясе яхшы иде һәм урнаштыру белән авырлык булмады. Узган ел кая куярга белми аптыраган идек. Шәхси тормышымда да бар да тәртиптә. Узган ел өйләнгән идем, быелның маенда улыбыз Кәрим туды. Аның һәр һөнәрен сөенеп күзәтәм.

:: Нәрсә көендерде?

– Алдагысына ышаныч булмау. Киләсе елда ни буласын алдан планлаштыра алмау эшкә бик зур комачаулык ясый. Ел нинди киләчәк, бәяләр ничек булачак? Боларны без берничек тә контрольдә тота алмыйбыз. Яшелчәчелектә дә, игенчелектә дә – шул ук хәл. Быел ашлыкның үзкыйммәте – 7 сум, ә 6 сумга саталар. Әле анысын да алучы юк, чөнки базарда кирәгеннән артык. Авыл хуҗалыгы продукциясен җитәрлек күләмдә генә җитештерергә кирәк. Әйтик, быел яшелчә уңышы уртача булды, шуңа күрә ул яхшы сатылды. Ә амбарлар узган елгы ашлык белән тулы иде. Шуңа күрә быелгысын урнаштыра да, яхшы бәядән сата да алмадылар.

:: Киләсе елдан ни көтәсез?

– Даимилек һәм ышаныч.

Равил ХИСАМОВ

Вазыйфасы һәм эш урыны: Нурлат районының Иске Әлмәт авылы башлыгы.

:: Быел авыл хуҗалыгы тармагында һәм шәхси тормышыгызда сезне нәрсә сөендерде?

– Барысы да тыныч кына, тәртип белән бара. Бүгенге мәшәкатьле тормышта әнә шунысы да бик кадерле. Референдум узып, үзара салым акчасы җыелып бетте. Узган ел җыелган акчага эшләр башкарылды, юллар каралды. Безнең җирлеккә караган, җиде кеше генә яшәүче Нариман авылында быел унар мең сум акча җыярга дип килештеләр. Аннан алдагы елда 38әр мең сум җыйганнар иде. Ул акчага авыл юлларына вак таш түшәдек.

:: Нәрсә көендерде?

– Авыл картая, сабыйлар тумый, күпчелек халыкны өлкән яшьтәгеләр генә алып тора. Менә шул борчый.

:: Киләсе елдан ни көтәсез?

– Бездә халык бердәм. Киләсе елларда шул бердәмлекне югалтмасак иде. Ил-көннәребезгә тынычлык, халкыбызга саулык телим.

Минталип МИННЕХАНОВ

Вазыйфасы һәм эш урыны: хуҗалык җитәкчесе, Россиянең атказанган фермеры.

:: Быел авыл хуҗалыгы тармагында һәм шәхси тормышыгызда сезне нәрсә сөендерде?

– Иң беренче чиратта, Адәм баласы оптимист булырга тиеш. Бөртеклеләрне, яшелчәләрне җыярга керешкәнче, бик нык корылык булды быел. Башта күңелдә шом барлыкка килгән иде. Ләкин без бик алдынгы технологияләр белән эшлибез, сугару машиналарыннан файдаланабыз. Шуның нәтиҗәсендә уртача уңыш булды һәм аларны вакытында җыеп ала алдык. Шуңа күрә артык зарланырга сәбәп юк. Ашлык чистарта, киптерә торган комплексны сафка бастырдык, су сиптерү җайланмаларына капиталь ремонт ясадык. Тагын бер яшелчә саклагыч төзибез, чөнки үстергән продукцияне куярга урын җитми. Әле менә быел тагын бер сөенеч: «Ел җитәкчесе» дип танылдым, зур чарада диплом тапшырдылар. Бу хезмәт кешесенә хөрмәтне күрсәтә инде. Безнең бу – династия белән эшли торган бизнес. Җәмәгатем белән икебезгә балалар ярдәм итә. Улыбыз Рамис – идарәче, кызыбыз – юрист та, баш хисапчы да. Уkuларын тәмамлап, оныкларыбыз да шушы эшкә кайтырга ниятли.

:: Нәрсә көендерде?

– Ягулык, ашламалар, корткычлардан саклану чаралары, төзелеш материаллары бәясе бик нык артты. Быел бу аеруча нык сизелде. Ә авыл хуҗалыгы продукциясе һаман да шул бәядән сатыла. Быел барлык запасны файдаланып эшләргә туры килде.

:: Киләсе елдан ни көтәсез?

– Ирешкән уңышлар белән тукталмыйча, алга барырга. Чыгымнарны компенсацияли торган ярдәм чаралары булса, хуҗалыклар азмы-күпме сакланып кала алыр иде. Матди-техник базаны ныгытып, үзебезнең продукцияне халкыбызның өстәленә җиткерергә насыйп булсын.

12 гыйнварда сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Динә ГЫЙЛАҖИЕВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

«Ана даны» медале безгә тиешме?

Биш бала үстерәбез. Башкаларга биргәндә, без дә «Ана даны» медале бирмәсләрме дип көткән идек. Кая барасын, нинди документ җыясын, кемнән сорыйсын да белмибез. Тиздән олы балабызга 18 яшь тула. Безгә тиеш микән ул?

Гөлчәчәк ИСЛАМОВА.
Арча районы

Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге җитәкчесе Рафаэль ГЫЙНИЯТУЛЛИН:
– «Ана даны» медале биш һәм аннан күбрәк балалары булган, аларны тәрбияләүгә җаваплы һәм намус белән караган, сәламәт тормыш рәвеше алып барган, балаларының сәламәтлеген, белем алуын, физик һәм әхлакый яктан үсешен тәэмин иткән, аларны шәхес буларак үстергән әниләргә бирелә. Медаль бирелгән вакытта балигъ булмаган балалар саны бердән дә ким булмаска тиеш. Иң кечесенә 3 яшь тулу мөһим. Болардан кала, медаль алуның тагын бер шарты – Россия гражданы булып, Татарстан территориясендә биш елдан озаграк яшәү. «Ана даны» медален бирү турындагы гаризаны оешма коллективы, җәмәгать берләшмәләре, дәүләт органнары, шул исәптән Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының урындагы органнары бирә. Ул исә Татарстан Президенты Указы нигезендә карала. Сез, үзегез яшәгән районның социаль яклау бүлегенә барып, төгәлрәк белешә аласыз.

Зыян өчен акча бармы?

Мин авыл клубында эшлим. Ташкүмер ягам. Аны ташырга, көлен түгәргә, утын алып кереп ягып җибәрергә кирәк. Тузаны да чыга. Акчам газ операторларыныкы кебек. Тузан сулаган өчен нигә акча түләмиләр икән миңа? Шушы сорау күптән борчый инде.

ФИДАИЛ.
Әтнә районы

Әтнә районының башкарма комитеты җитәкчесе Айрат КАЮМОВ:
– Бу хакта беренче тапкыр сездән ишетәм. Нигә райондашларыбыз турыдан-туры безгә мөрәҗәгать итмиләр икән? Фидаил абыйны беләбез бит инде без. Район мәдәният йортыннан аның хезмәт хакын белештем. Кызганыч, газ операторына да, ташкүмер ягучыга да бертөрле түләнә. Әмма Фидаил абыйның ташкүмер ташуын, көлен түгүен, утын белән ягуын һәм тузанлы эштә эшләвен искә алып, аңа район мәдәният бүлеге өстәмә акча түләү җаен тапкан. Ул үзенә тиешен ала.

Өстәмә ял бирерләрме?

Авыру бала үстерүче әти-әниләр үзләренә тиешле ялны берләштереп алу хокукына ия дип ишеткән идем. Инвалид балам булса да, бер генә көнен дә алганым юк. Мөмкин булса, киләсе елда шушы ял көннәрен җыеп алмакчы идем. Шуны аңлатсагыз иде.

Гүзәл ШӘЙХИЕВА.
Казан

Россия Социаль фондының Татарстан бүлеге матбугат үзәге җитәкчесе Альбина НИКАНДРОВА:
– Айга дүрт көн тәшкил иткән мини-отпуск ата-аналарга, опекуннарга һәм попечительләргә бу көннәрне инвалид баланы тәрбияләүгә багышлый алсын өчен бирелә. Гомумән алганда, әти-әниләргә ял көне өчен акча түләнгән. Быел сентябрьдән өстәмә ял көннәрен уңайлырак форматта кулланып була. Хәзер ата-аналар, файдаланылмаган ял көннәрен җыеп бару мөмкинлегеннән файдаланып, 24 көнлек өстәмә ялны бала карауга багышлый ала. Хезмәткәр эш бирүче белән яллар датасын килештерергә һәм кадрлар бүлегенә тиешле гариза бирергә тиеш була.

Ярты бәя түләтмәсләрме?

Миңа – 91 яшь. Олы яшьтә булсам да, «ВТ»ны алдырам, укып барам әле. Сезгә бер соравым бар иде. Өемә телефон кертелгән. Ай саен шуның өчен 345 сум акча түлим. Бик сөйләшмәсәм дә, өздереп атасын килми. Пенсиям дә күп дип әйтеп булмый, 22 мең сум алам. Миңа өй телефоны өчен ярты гына бәя түләтсәннәр иде. Шуны белешегез әле.

Нурзидә ИБРАҺИМОВА.
Зәй районы Кушъелга авылы

Зәй районының социаль яклау бүлеге:
– Без бары тик сорау бирүченең үзенә генә мәгълүмат бирә алабыз. Бу апага безгә шалтыратып белешергә киңәш итәбез. Әгәр «Хезмәт ветераны» исеме булса, аңа ташлама булырга тиеш. Барысын да ачыклар өчен, үзенең документлары кирәк. Без аның Республика матди ярдәм күрсәтү үзәгенең Зәй бүлегенә мөрәҗәгать итүен сорыйбыз. 7-10-46 телефон номерына шалтыратырга киңәш итәбез.

Юл билгесе кайчан булыр?

Авылга керә торган юлдагы куркынычсызлык мәсьәләсе борчый. Эш шунда ки, авыл аша Норлат ягыннан килүче олы юл уза. Авылның Чишмә һәм Почтовая урамнары тоташып, авыл башында әнә шул олы юлга чыккан чатта ике яктан килүче транспорт маңгайга-маңгай очрашканчы, бер-берсен күрми. Бу мәсьәлә авыл халкын күптән борчый. Машиналар хәрәкәтенә куркыныч тудыручы чатка махсус юл билгесе куюларын сорап, Яшел Үзәнгә дә бардым инде. Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Юрий Камалтынов кабул иткән вакытка туры килдем. Ул мине бик игътибар белән тыңлады, хәлебезгә керде. Аның ярдәме белән авыл башындагы әлеге юл чатына өч юл билгесе куеп киттеләр. Болар – авыл исеме, тизлекне 40 чакрымга кадәр чикләү һәм билгеле бер аралыкта узып китү тыелу турындагы юл билгеләре. Тикшереп торучы булмагач, бирелгән сәгатенә 40 чакрым белән генә хәрәкәт итүчеләр сирәк. Акрынрак йөрсәләр, узып китү тыелу турындагы юл билгесе дә кирәкмәс иде. Авылның ике урамыннан чыгучы машиналар олы юлдан килүче автомобильләрне күрми. Норлат ягыннан килүчеләр дә, юл билгесе булмагач, бу урында юлга машина килеп чыгарга мөмкин икәнен чамаламый. Башка юл билгеләрен куеп киттеләр, тик иң кирәклесе – «Икенчел дәрәҗәдәге юл тоташкан урын» («Примыкание второстепенной дороги») дигәне юк. Шул чатка кергәндә йөрәк дөп-дөп сикерә. Авылдан яңадан хат та яздык. Юл билгесе куярга ярдәм итсеннәр иде.

Ризван МОХТАРОВ.
Яшел Үзән районының
Татар Әҗәлесе авылы

Татарстан Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының матбугат хезмәте җавап бирә:
– Әлеге мөрәҗәгать буенча ЮХИДИнең Яшел Үзән муниципаль районындагы бүлегенә Татар Әҗәлесе авылында 2.3.1. «Икенчел дәрәҗәдәге юл кисешү» юл билгесен урнаштыру эшен килештерүгә бәйле хат юлланды. Уңай җавап алынган очракта, әлеге юл билгесе, һава шартлары мөмкинлек бирүгә, 2024 елның язгы-җәйге чорында урнаштырылачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Карауччы булмаса нишләргә?

Әнигә икенче елга 80 яшь тула. Караучы булса, 1200 сум акча түләнә, диделәр. Авылда аны карарлык кеше юк. Ул акчаны алырга теләгән кешенең беркайда эшләмәве кирәк. Мин әлегә эшлим. Әнинең дәүләт биргән акчаны аласы да килә бит. Безгә нишләргә соң?

Венера НУРМӨХӘММӘТОВА.
Яңа Чишмә районы

Россия Социаль фондының Татарстан бүлеге матбугат үзәге җитәкчесе Альбина НИКАНДРОВА:
– 80 яшьтән узган кешеләргә, аларны тәрбияләүче кеше булган очракта, пенсияләренә өстәп, 1200 сум акча түләнә. Шуны да искә төшерәбез: караучы кешегә бу эше өчен пенсиясенең иминият өлешенә һәр ел өчен 1,8 коэффициент өстәлә. Күрше авылларда әби-бабайлар караучы кешеләр юкмы? Ул кешегә берничә кешене карарга да ярый бит. Сезгә бу хакта район социаль яклау бүлеге аша белешергә кирәк.

Категориясе кире кайтамы?

Хатыным балалар бакчасында музыка җитәкчесе булып эшли иде. 1 нче категориясе бар. Быел икенче бакчага психолог булып күчте. Аңа категориясе бетәчәген әйткәннәр. Әгәр ул музыка укытучысы буларак дәресләр укыта башласа, категориясе кире кайтарыламы?

Алмаз ГАЙНУЛЛИН.
Казан

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат үзәге белгече Айгөл НӘБИЕВА:
– Музыка укытучысы белән психолог эше – икесе ике вазыйфа. Шуңа күрә, вазыйфасын алыштыргач, категориясе бетә. Әгәр инде бу ханым музыка дәресләре алып бара башлый икән, категориясенең вакыты чыкмаган булса, акчасын түлиләр.

Фикер

Көн дә ипи сатып алабыз. Узган ел ипи бәясе 37 сум иде, быел 38 сум булды. Әмма көннән-көн, сизелеп, авырлыгы кими. Ягулык салу станцияләрендә бензин күләмен контрольдә тоткан кебек, ипинең дә авырлыгын тикшереп торсыннар иде ул. Алайса, бигрәк алдыйлар бит.

Гатуф БӘДРӘШИТОВ. Актаныш

Казан эчендә хәрәкәт итүче 89 нчы маршрут автобусы бик начар йөри. Җәй буе мичләре эшли, түзеп булмаслык эссе. Ә кышын салкын. Бушка йөртмиләр бит, сыйфатлы хезмәт күрсәтсеннәр иде.

Рәзинә СӘМИГУЛЛИНА. Казан

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

1 гыйнвар | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

Вещание не предусмотрено

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.35 «КАЗАНГА КАЗАНДА» 16+
07.40 Мультфильмы 6+
08.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 16+
11.00 «Пар алма» 16+
12.00 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 16+
15.15 «Өмет йолдызы» 16+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.30 «ЯҢА ЕЛДА БЕРГӘ БУЛЫЙК!» 16+
19.30 «Болгар радиосы» XI Милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасы 12+
22.30 «НАЗАД – К СЧАСТЬЮ, ИЛИ КТО НАЙДЁТ СИНЮЮ ПТИЦУ?» 16+
00.20 «Шалт, Мөхәммәтҗан!» 16+
02.25 «Секреты татарской кухни» 12+
02.50, 03.40 «Каравай» 6+
03.15 «Музыкальный майдан» 16+
04.05 «Гаилә учагы» 16+
04.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Татарлар» 12+
06.40 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.35 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
08.40 «Гаилә учагы» 16+
09.10 «Яңа елда минем гаиләм» 16+
10.00 «АЛМАШ» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
13.00 «Хәситә» 16+
14.35 «Чакыра юлларым» 16+
16.15 «Кәмит Җәвит» 16+
17.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
19.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
19.30 «Болгар радиосы» XI Милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасы 12+
22.50 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.40 «СИҢА КАЙТАМ» 16+
02.00 «Яңа Гасыр»да Яңа ел төне» 6+

1 КАНАЛ

06.00 «Новогодний календарь» 0+
06.50 «МАРЬЯ-ИСКУСНИЦА» 0+
08.05 «КАРНАВАЛЬНАЯ НОЧЬ» 0+
09.20 «МОСКВА СЛЕЗАМ НЕ ВЕРИТ» 12+
10.00, 12.00 Новости
12.15 «МОРОЗКО» 0+
13.35 «Наш Новый год» 12+
14.00 Новогодний «Мечталлион» 12+
16.30 «ИВАН ВАСИЛЬЕВИЧ МЕНЯЕТ ПРОФЕССИЮ» 0+
18.00 Вечерние новости
18.30 «Большая разница 2024» 16+
20.00 «ВЫЗОВ» 12+
22.35 «НОВОГОДНЕЕ ПРИКЛЮЧЕНИЕ» 16+
00.10 «Самый первый Новый год» 18+
01.55 «Наш Новый год» 12+
03.35 «Легенды «Ретро FM» 12+

РОССИЯ 1

04.20 «ИРОНИЯ СУДЬБЫ, ИЛИ С ЛЁГКИМ ПАРОМ!» 12+
07.40 «ДЕВЧАТА» 0+
09.20 «ДЖЕНТЛЬМЕНЫ УДАЧИ» 6+
10.50 «БРИЛЛИАНТОВАЯ РУКА» 0+
12.35 «ОДЕССКИЙ ПАРОХОД» 12+
14.00, 20.00 Вести
14.25 «Песня года»
16.25 «ПОСЛЕДНИЙ БОГАТЫРЬ: ПОСЛАННИК ТЬМЫ» 6+
18.10 «КОНЁК-ГОРБУНОК» 6+
20.24 «ХОЛОП» 12+
00.05 «МАЙОР ГРОМ: ЧУМНОЙ ДОКТОР» 12+
02.25 «Падал прошлогодний снег» 0+
02.45 «ЧЕРНОВИК» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 «Лига героев» 12+
07.00 Танцевальный спорт. Латиноамериканские танцы. Кубок Кремля «Гордость России!» 0+
08.00 «Спорт Тоша» 0+
08.15 Все на Матч! 12+
09.45 «КОМАНДА МЕЧТЫ» 6+
11.05 Битва роботов 12+
11.55 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Гонка преследования. Мужчины
12.45, 15.20, 20.00 «Вы это видели» 12+
14.25 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Гонка преследования. Женщины
15.55 Прыжки на лыжах с трамплина. «Турне 4-х трамплинов»
17.55 Хоккей. Чемпионат мира 2011. Молодёжные сборные. Финал. Россия – Канада 12+
21.50 Смешанные единоборства. UFC. Ислам Махачев против Александра Волкановски 16+
00.00 «Лица страны» 12+
01.15 «География спорта» 12+
02.30 Художественная гимнастика. Небесная грация 6+
04.05 Футбол. Лига чемпионов. «Бавария» (Германия) – «Манчестер Юнайтед» (Англия) 6+

НТВ

05.00 «Следствие вели...» 16+
06.20 «ПАПЫ» 6+
08.00 «ЛИХАЧ» 16+
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
15.30 «Новогодний миллиард»
17.00 «КИНО ПРО БАНДИТОВ» 16+
20.20 «Шоу Аватар» 12+
23.15 «ГАРАЖНЫЙ ПАПА» 12+
01.00 «ВЕЗЁТ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 05.35 «Домашняя кухня» 16+
06.55 «Пять ужинов» 16+
08.25 «МЕСТЬ И ЗАКОН» 16+
11.40, 22.50 «ЗИТА И ГИТА» 16+
14.05 «ТАНЦОР ДИСКО» 16+
16.30 «ТАНЦУЙ, ТАНЦУЙ» 16+
19.00 «МУЖЧИНА В МОЕЙ ГОЛОВЕ» 16+
21.05 «ВОСПИТАНИЕ И ВЫГУЛ СОБАК И МУЖЧИН» 16+
01.10 «Наш Новый год. Романтические шестидесятые» 16+
02.00 «Наш Новый год. Душевные семидесятые» 16+
03.15 «Наш Новый год. Золотые восьмидесятые» 16+
04.25 «Наш Новый год. Лихие девяностые» 16+
06.25 «ИСПЫТАТЕЛЬНЫЙ СРОК» 16+

ЗВЕЗДА

04.45 «Галерея звезд» 12+
11.05 «БАБИЙ БУНТ, ИЛИ ВОЙНА В НОВОСЕЛКОВО» 16+
21.30 Праздничный концерт, посвященный 100-летию газеты «Красная Звезда» 6+
23.35 «ЛЮБЭ. Юбилейный концерт Николая Расторгуева» 6+
01.25 «КВАТРО» 6+
02.25 «ГОРИ, ГОРИ, МОЯ ЗВЕЗДА» 12+
04.00 «Москва фронту» 16+
04.30 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ» 16+

2 гыйнвар | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

14.40, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 00.30 «ТРИ МУШКЕТЁРА» 12+
08.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 16+
11.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Ялт-йолт» 16+
15.40 Концерт Мурада Гайсина 16+
17.05 «Әйдә, шаяРТ!» 16+
19.00 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 12+
19.30 «Хәситә» 16+
21.00 «Яңа Гасыр»да Яңа ел төне» 12+
23.00 «С НОВЫМ ГОДОМ, МАМЫ!» 12+
02.25 «Секреты татарской кухни» 16+
02.50, 03.40 «Каравай» 6+
03.15 «Музыкальный майдан» 16+
04.05 «Гаилә учагы» 16+
04.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 02.00 «Татарлар» 12+
06.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.25 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
08.40 «Гаилә учагы» 16+
09.10 «Яңа елда минем гаиләм» 16+
10.00 «АЛМАШ» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
13.00 А. Цагарелли. «Ханума». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
16.00 «Кәмит Җәвит» 16+
17.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
19.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
19.30 «Татарлар» 12+
20.00 «Безнең заман – Наше время» республика телевизион фестиваленең гала-концерты 16+
22.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
22.50 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК» 16+
02.20 «Көлке чыбыркысы» 16+
05.10 «Бөркет канатында хөрлек бар» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.10 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+
06.30 «МОРОЗКО» 0+
08.00 «Доброе утро»
10.15 «Модный приговор» 0+
11.10 «Играем свадьбу!» 12+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.20 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
15.15 «Угадай мелодию» 12+
16.05 «КАЗАНОВА» 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Я люблю мою страну» 0+
19.25 «Сегодня вечером» 16+
21.00 «Время»
21.35 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ» 16+
23.25 «ДИАНА ДЕ ПУАТЬЕ» 16+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

05.10 «ДНЕВНИК СВЕКРОВИ» 12+
06.45 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ» 12+
08.40 «Утренняя почта»
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.55 «КОНЁК-ГОРБУНОК» 6+
14.40, 21.05 Вести. Местное время
14.55 «Песня года»
17.50 «ЧЕБУРАШКА» 6+
21.20 «ТАЙНА ЛИЛИТ» 12+
01.30 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Лига героев» 12+
07.00 «Год российского спорта» 12+
08.00 «Спорт Тоша» 0+
08.15 «Царица Тамара. Быкова» 12+
09.30 «Ярцев. Вечное сияние» 12+
10.30 «Самый лучший тренер в мире – Павел Фёдорыч Садырин!» 12+
11.50 «Мы, игроки сборной России...» 12+
12.50 «Лев Яшин – номер один» 6+
14.00 «Валерий Харламов. На высокой скорости» 12+
15.00 «Магия большого спорта. Хоккей» 12+
15.25 Прыжки на лыжах с трамплина. «Турне 4-х трамплинов»
17.00 «Финт Боброва» 12+
19.30 «Магия большого спорта. Футбол» 12+
20.00 «Вы это видели» 12+
21.50 Все на Матч!
22.35 Матч! Парад 16+
23.35 «Кулачные бои» 16+
01.15 «География спорта» 12+
02.30 Художественная гимнастика. Небесная грация 6+
04.05 Футбол. Лига чемпионов. «Наполи» (Италия) – «Реал» (Мадрид, Испания) 6+

НТВ

05.15 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «АЛМАЗ В ШОКОЛАДЕ» 12+
10.20 «Детская Новая волна» 0+
12.15 «БАЛАБОЛ» 16+
19.30 «БИМ» 16+
22.40 «Главный новогодний концерт» 12+
01.05 «Секрет на миллион» 16+
02.00 «КИНО ПРО БАНДИТОВ» 16+

ДОМАШНИЙ

08.15 «НЕ МОГУ СКАЗАТЬ «ПРОЩАЙ» 16+
10.10 «ЕЩЁ ОДНА ПОПЫТКА ПОЛЮБИТЬ» 16+
14.40 «С ДНЁМ РОЖДЕНИЯ, ВИКА!» 16+
19.00 «ЖЕНУ ВЫЗЫВАЛИ?» 16+
23.20 «ТАНЦОР ДИСКО» 16+
02.10 «ТАНЦУЙ, ТАНЦУЙ» 16+
04.30 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
06.05 «Предсказания: 2024» 16+

ЗВЕЗДА

07.30 «СЕМЬ НЯНЕК» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15 «Загадки века» 12+
21.00 «ДЕВУШКА С ГИТАРОЙ» 12+
22.55 «НЕБЕСНЫЕ ЛАСТОЧКИ» 12+
01.15 «ДЕВУШКА С ХАРАКТЕРОМ» 12+
02.40 «Фронтовые истории любимых актеров. Юрий Никулин и Владимир Этуш» 16+
03.30 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ» 16+

ТАШЛАМАЛАР һәм ГАРАНТИЯЛӘР HEROES.TATAR 117

- РОССИЯ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ ХИСАБЫНА ТУПЛАНМА-ИПОТЕКА СИСТЕМАСЫ АША ТИЗ АРАДА ТОРАК САТЫП АЛУ МӨМКИНЛЕГЕ
- ХЕЗМӘТ УРЫНЫННАН ТОРАК ЯКИ ТОРАКНЫ НАЙМГА АЛЫП ТОРГАН ӨЧЕН КОМПЕНСАЦИЯ
- ХӘРБИ-МЕДИЦИНА УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕНДӘ БУШЛАЙ ТИКШЕРЕНУ, ДӘВАЛАНУ ҺӘМ РЕАБИЛИТАЦИЯ УЗУ
- ФЕДЕРАЛЬ БЮДЖЕТ ХИСАБЫНА ГОМЕРНЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ ИМИНИЯТЛӘШТЕРУ
- 20 ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТКӘННӘН СОҢ ТАШЛАМАЛЫ ПЕНСИЯ АЛУ ХОКУКЛАРЫ
- ХӘРБИ ХӘРӘКӘТЛӘР ВЕТЕРАНЫ СТАТУСЫ ҺӘМ ТИЕШЛЕ ТАШЛАМАЛАР
- КРЕДИТ ҺӘМ САЛЫМ КАНИКУЛЛАРЫ
- БАЛАЛАРНЫ ВУЗДА БУШЛАЙ УКЫТУ
- БАЛАЛАРГА ҖӘЙГЕ САВЫКТЫРУ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА БУШЛАЙ ЯЛ
- КОНТРАКТ БУЕНЧА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРГӘ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫННАН БЕРДӘМ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР, ТАШЛАМАЛАР ҺӘМ ГАРАНТИЯЛӘР

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

АЛДАН ХӘСТӘРЕН КҮРӘСЕ

Яңа ел төненнән соң да тормыш бар! Белгечләр көтеп алган бәйрәм кичендә шул хакта да истән чыгармаска киңәш итә. Организмга зыян салмыйча, гадәти тормышка кайтуның да рәте бар, ди алар. Алдан хәстәрен күрү бу очракта да артык түгел, кыскасы.

Табиб-терапевт Гөлназ ШӘЙДУЛЛИНА шул уңайдан киңәшләр бирде.

1 Яңа ел төнендә артыгын ашап ташлаган булсагыз, 1 гыйнвар көнне ризыктан тыелып тору хәерле. Ашказанына тагын да зуррак зыян китермәсен өчен, тамагыгыз ачкач кына ашарга тырышыгыз. Тамак ачсын өчен исә 15–20 минут саф һавада йөреп керү дә җитә. Моннан тыш, ул баш авыртуын да баса.

2 Әрәм булмасын дип, Яңа ел өстәленнән калган салатларны да ашарга ярамый. Чөнки салатлар күп дигәндә бер тәүлек кенә сакланырга тиеш. Өстәвенә аларны ясаганда кулланылган майонез, соуслар микробларның үрчүен тизләтә. Шуңа күрә Яңа ел табынына дип алдан ясап куелган салатны ашап агуланырга да мөмкин.

3 Ашказаны эшләп китсен өчен, иртән торуга бер стакан җылы су эчеп кую әйбәт. Алдагы көнне исерткеч эчемлек кулланган кешегә көн дәвамында күпләп чиста су эчәргә кирәк. Җиләкләрдән ясалган морс, минераль су, лимонлы су да ярдәм итәчәк.

4 Ашказаны акрынлап гадәти ризыкларга ияләшсен өчен, бәйрәмнән соң күбрәк яшелчә, яшел тәмләткечләр ашарга кирәк.

5 Яңа ел төнендә мулдан ашаганнан соң кисәк кенә диетага утырырга да ярамый. Бу организм өчен икеләтә стресс булачак. Ашкайнату системасы белән проблемалар да башланырга мөмкин.

6 Махмырдан тилмергәндә порошок рәвешендәге сорбент яки активлаштырылган күмер эчәргә кирәк. Аннан соң күпләп су эчеп, ярты сәгать – бер сәгать дәвамында берни ашамыйча тору хәерле.

vk.com

7 Яңа ел табынынннан соң ашказаны, эчәклек эшчәнлеге бозылса, гадирәк ризык ашарга кирәк. Майлы, ачы ризыклар, әзер соуслар ашаудан тыелып тору хәерле. Йокларга ким дигәндә өч сәгать кала ашаудан тыелып торырга кирәклеген дә онытмагыз.

8 Әгәр ашказаны-эчәк системасында хилафлык сизсәгез, баш авырту, хәлсезлек, күңел болгану борчыса, җиңелчә бушану диетасы тотыгыз. Ул кечкенә порцияләр белән җиңелчә аш, сыек ботка, кош итенә, балыкка өстенлек бирүдән гыйбарәт.

Файдалы

Иммунитетны ныгытабыз

1 нче рецепт

Кирәк: *имбир тамыры – 300 грамм, кабыгы белән бер-ике лимон, бал – 150–200 грамм.*

Иң элек 300 грамм имбирне кабыгыннан чистартып, угычта уарга яки иттарткычтан чыгарырга кирәк. Лимонны кайнар су белән пешеклибез, төшләрен алып, вак кына итеп турыйбыз. Имбир белән лимонны бергә кушабыз да, шуның өстенә бал агызып, әйбәтләп болгатабыз. Килеп чыккан массаны пыяла савытка тутырып, суыткычка куябыз. Аны шушы савытында 2 айга кадәр сакларга була.

Әлеге витаминлы катнашманы иртән ач карынга 1 чәй кашыгы күләмендә кулланырга кирәк, аның артыннан җылы су йотып кую яхшы. Ашказаны-эчәк авырулы кешеләргә бу катнашманы кулланырга киңәш ителми.

2 нче рецепт

Кирәк: *бал – 3 аш кашыгы, мүк җиләге (клюква) яки нарат җиләге (брусника) – 0,5 кг, лимон яки әфлисун – 1 данә.*

Иң элек бүлмә температурасындагы мүк җиләген юып киптерергә кирәк. Лимонны зур булмаган кисәкләргә бүләргә, соңыннан икесен дә вакларга: иттарткычтан чыгарырга яки блендер белән изәргә. Соңрак шуңа бал салып, банкага тутырып, суыткычта сакларга кирәк. Шуны көнгә 2 тапкыр 2шәр чәй кашыгы кабул итәргә. Әлеге катнашма ярдәмендә 3–4 атна дәвамында дәваланырга киңәш ителә.

3 нче рецепт

Кирәк: *балавыз – 2 аш кашыгы, аракы – 250 мл.*

Балавызны аракыда 10 тәүлек тирәсе төнәтәбез. Әзер булгач сөзәбез. Олылар көненә ике тапкыр бер бал кашыгы күләмендә эчәргә тиеш. Тәмгә бик тәмсез, әче ул. Шуңа балаларга бер стакан сөткә 3–4 тамчы тамызып бирегез. Бу дару иммунитетны ныгытып кына калмый, авыру башлангач та шушы төнәтмәне эчсәгез, көн ярымда файдасы тими калмас.

4 нче рецепт

Кирәк: *бер үк күләмдә сарымсак белән бал.*

Сарымсакны угыч аша чыгарып, 1:1 күләмендә бал белән болгатабыз. Ашар алдыннан көнгә өч тапкыр берәр бал кашыгы кабабыз. Артыннан су эчеп куябыз.

Табигать даруханәсе

Канәфер булыша

Әлеге хуш исле тәмләткеч бета-каротинга, В төркеме витаминнары, С, Е витамины, эфир майларына бай. Киптерелгән канәфер күп авырудан котылырга ярдәм итә.

✓ Авыз куышлыгында проблемалар булса, теш сызласа, казналык ялкынсынса, стоматит интектерсә, авыздан ис килсә, канәфер чәйнәргә кирәк. Ангина башланганда да әйбәт дәва ул.

✓ Ашарга 15 минут кала 1–2 канәферне 1 чәй кашыгы бал белән чәйнәргә киңәш ителә. Ләкин ашказаны җәрәхәте булганда һәм уникеилле эчәк авыртканда, кан басымы югары чакта канәфер зыянлы булырга мөмкин.

✓ Канәфер мае – артрит, артрозлардан да үтемле чара. Ул авыртуны кимәтә, ялкынсынуны бетерә. Аның белән буыннарга массаж ясыйлар. Моның өчен 1 аш кашыгы массаж маена канәфернең эфир маен 15 тамчы кушарга кирәк.

✓ Кан басымы төшсә, берничә канәфер орлыгы чәйнәргә кирәк, кофеин кебек үк тәэсир көченә ия ул.

Ютәлдән – мандарин кабыгы

Мандаринны юып әрчисең дә кабыгын кайнап торган ике стакан суга салып кайнатасың. Суынгач, сөзеп, көненә өч тапкыр ярташар стакан эчәсең.

Үзем сынадым

ҖЫЕРЧЫКТАН КОТКАРА

Биттәге вак җыерчыкларны киметүнең җаен таптым бит. Моның өчен банан кабыгы бик әйбәт икән. Банан кабыгының йомшак ягы белән биткә 20 минут дәвамында массаж ясыйм. Ул битне бик яхшы дымландыра, вак җыерчыклар да кими.

Алсу ВӘЛИЕВА. Казан

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

СЫЙЛАНА БЕЛЕП СЫЙЛАН

Яңа елга аяк басарга санаулы сәгатьләр калып бара. Елның иң сыйлы бәйрәмен сәламәтлеккә зыян салмый гына ничек каршыларга? Табын әзерләгәндә нәрсәләргә игътибар итәргә?

Нутрициолог, дөрес туклану белгече Чулпан МӨСЛИХОВА тәмле һәм файдалы Яңа ел табыны корырга ярдәм итте.

Файдалы «Оливье»

1 нче САЛАТ. Яңа ел өстәлен «Оливье» салатыннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Калорияле сапалган салатны зыянсыз итеп тә ясарга мөмкин. Аның өчен бәрәңге, пешкән ит, тозлы кыяр, пешкән кишер, чи суган, составында шикәр булмаган консервланган борчак кирәк, ә майонезын үзебез ясыйбыз. Моның өчен өч йомырка сарысы, бер аш кашыгы зәйтүн мае, лимон согы, бер чәй кашыгы горчица, өч аш кашыгы каймак яисә йогырт кирәк. Барысын бергә блендер белән болгатасың. Әлеге майонез 2 көн саклана. Диабет белән авыручыларга бәрәңге урынына батат яисә ак фасоль кулланырга була.

2 нче САЛАТ. Әлеге салат «Оливье»ны да алыштыра ала. Пекин кәбестәсен, кыярны озынча итеп турыйбыз, алар янына тавыкның түш итен шакмаклап салабыз, шикәрсез консервланган борчак, төменчә суган, тоз һәм өйдә ясалган майонез белән болгатабыз. Туклыклы, тәмле, аз калорияле салат әзер!

3 нче САЛАТ. Руккола белән моцареллалы тәмле, ансат ясала торган салат та табын яме булыр. Сай тәлинкәгә руккола салабыз, аның өстенә черри помидорларын, моцарелла сырын куябыз. Өстенә лимон согы сыгабыз, әз генә зәйтүн мае сибәбез, төменчә тоз, борыч өстибез. Шулай ук бәлзәм серкәсе дә салырга мөмкин. Әлеге салатны хөрмә, гранат һәм әстерхан чикләвеге салып төрләндерергә дә була.

vk.com

Ясап карагыз әле, тәмле дә, файдалы да, матур да килеп чыга.

Каз-үрдәк киви сорый

Салаттан соң әкренләп аксымлы ризыкка күчсәк тә була. Алма, әфлисун белән пешерелгән каз, үрдәк, үз согында пешкән тавык ите яисә тәмләткечләр белән пешерелгән кызыл балык, койка бик отышлы була. Аны һәркем үзе теләгән рецепт буенча пешерә. Әгәр каз, үрдәк майлырак булса, алар артыннан имбир, ананас, киви яисә әчетеп тозланган кәбестә кабып куегыз. Кивида, мәсәлән, актинидин дигән фермент бар. Ул аксымны таркатырга ярдәм итә, ашкайнату системасын активлаштыра. Әчетеп тозланган кәбестә исә эчәклек системасы өчен файдалы, сару кайнау, кикереп интегүдән коткара. Табынга санап үтелгән ризыкларны куйсагыз, ашкайнату системасының никадәр җиңелрәк эшләгәнен үзегез дә сизәчәксез.

Җиңел аш

Табында итле ризыклар күп булганлыктан, пилмән, токмачлы аш урынына җиңелчәрәк ашлар пешерсәгез дә була. Мәсәлән, кабак, гөмбә, ясмык аш-боламыклары шундыйлардан.

Гөмбә ашы пешерү өчен, 500 г шампиньон, ике бәрәңге, бер баш суган, 200 мл кокос сөте, бер аш кашыгы зәйтүн мае һәм төменчә тоз белән борыч кирәк була. Шакмаклап туралган бәрәңгене тозлы суда кайнатырга. Башта суганны зәйтүн маенда кызарганчы кыздырырга һәм аңа туралган гөмбәне өстәп, тагын 8–10 минут кыздырып алырга. Бәрәңге кайнаган шулпага гөмбәне салып кайнатып чыгарырга һәм блендерда изәргә. Кокос сөте өстәп кайнатып чыгарырга һәм сүндереп 10–15 минут торганнан соң ашарга.

Бәлеш оны ак булмасын

Татар гаиләсендә бәйрәм итле бәлешсез уза димени?! Бәлешнең кандагы шикәр күләмен күтәрү дәрәҗәсен киметү өчен, югары сортлы ак онны эре бөртекле онга алмаштырырга кирәк. Бәрәңгесен иртәдән үк әрчеп, турап, салкын суга салып куйсагыз яхшы. Ә калориясен киметү өчен, бәлешне яшелчәләр белән ашагыз.

ТАТЛЫ СУ КУЙМАГЫЗ

Эчемлекләргә килгәндә өстәлгә татлы, газлы сулар куярга тырышмагыз. Аксымлы, майлы ризыклар белән бергә кушылса, эчәклектә әчешү китереп чыгарачак, метеоризм булырга, ашказаны ризыкларны эшкәртмәскә мөмкин. Өйдә кайнатылган компот, җиләкләрдән ясалган шикәрсез морсларга өстенлек бирегез. Шулай ук өстәлгә гади җылы су да куегыз. Графинда матур итеп куренсен өчен, аңа лимон кисәкләре, бөтнек яфраклары, виктория, кыяр кисәге салып җибәрергә мөмкин.

КАБЫМЛЫК – БЕР ТАБЫНЛЫК

1 нче кабымлык. Арыш ипие өстенә сарымсак һәм йогырт белән болгатылган чөгендер сылыйбыз, аның өстенә кечкенә кисәк сельдь балыгы куябыз, дижон горчицасы һәм укроп, петрушка белән бизибез.

2 нче кабымлык. Ләвәшкә эремчекле сыр сылыйбыз, бер рәткә яшел салат яфраклары, икенче рәткә кызыл балык кисәкләре, өченче рәткә тагын яшел салат яфраклары куйбыз да ләвәшне төрәбез һәм божралап кисәбез.

3 нче кабымлык. Өстәлне бизәр өчен канапэлар да ясарга мөмкин. Мәсәлән, угычта уылган сыр, кишер, сарымсакны каймак белән болгатып, помидор өстенә куябыз. Ә кыяр өстенә гуакамоле сылыйбыз, аның өстенә пешкән креветка куябыз. Сырны өчпочмаклап кисәбез, өстенә райхан яфрагы, кипкән помидор кисәге һәм зәйтүнне таякчык белән беркетәбез.

Белеп тор!

✓ Бәйрәмне «Оливье»дан башламагыз! Башта яшелчә салаты ашагыз. Шулай итсәгез, өстәл янында артыгын ашаудан тыелачаксыз һәм кандагы шикәр күләме дә, клетчатка кергәч, кисәк кенә югары күтәрелмәячәк.

✓ Кибет казылыкларын натураль казылыкларга алыштырыгыз. Натрий глутаматы кушылмаган, табигый тәмләткечләр белән ясалган казылыкларга өстенлек бирегез. Шулай ук өстәлгә пешкән тел куярга да мөмкин. Горбуша, кета балыкларын кечкенә кисәкләргә турап, кабымлык итеп пешереп куярга мөмкин.

✓ Өстәлдә ризыклар төрле, әмма мулдан булмасын. Берничә көнгә җитәрлек итеп ясамагыз. Һәр көнне рационны төрләндереп торсагыз, күпкә файдалырак булачак. Яңа елны каршылаганда сыйлана белеп сыйланыйк!

Психолог киңәше

Үзебезне онытмыйк

«Яңа ел мәшәкате дип, үзебез турында онытмаска кирәк!» – ди психолог, коуч Лилия Дәүләтшина. Аның түбәндәге 5 киңәше файдага булыр.

1 Нәтиҗә ясагыз. 10 минут вакыт табып, язып яки көндәлегездән узган елның һәрбер аен барлап чыгыгыз. Мәсәлән, гыйнварда, февральдә... ноябрьдә нинди вакыйгалар булды? Нинди уңышларыгыз өчен үзегезне мактый аласыз? Алар өчен үзегезгә рәхмәт әйтегез. Нинди авыр мизгелләр кичерергә туры килде? Көндәлегездә авыр хисләр кузгалса, аларга урын бирегез. Үзегезне үзегез ишетергә теләгән сүзләр белән юатыгыз. Ахырдан декабрь аеның көндәлдә калган мизгелләрен барлап чыгыгыз да узып баручы елга чын күңелегездән рәхмәт әйтегез.

2 Рәхмәт әйтегез. Узып барган елда терәк булган, сезнең уңышларыгызда ярдәм иткән туганнарыгыз һәм якыннарыгызны искә төшереп, рәхмәт әйтегез. Рәхмәтегезне язып, шалтыратып яки күрешеп тә җиткерергә мөмкин.

3 Ревизия ясагыз. Узып баручы елдагы нинләр белән саубуллашырга телисез һәм кайсыларын киләсе елга үзегез белән аласыз? Язып куегыз. Мәсәлән, курку, ялкаулык, авыру, негатив уйларны узган елда калдырабыз.

4 Ачыклагыз. Киләсе елда нәрсәне булдырырга һәм көчәйтергә телисез? Исемлеген төзегез. Мәсәлән, «сәламәт, кыю, шат булырга, күп итеп сәяхәт кылырга, спорт белән шөгыльләнергә телим».

5 Максат һәм теләкләрне барлагыз. Киләсе 2024 ел өчен теләк һәм максатларыгызны языгыз. Үзегезгә һәм гаиләгезгә, илгә һәм, гомумән, бөтен дөньяга бәйле нинди теләкләрегез бар – һәммәсен языгыз. Иң мөһиме – киләсе ел имин һәм тыныч ел булсын!

БӘХЕТТӘ ДӘ ИСКӘ АЛ

Узып баручы елның соңгы көннәрен ваклыйбыз. Яңа елга яңа өмет, хыяллар белән аяк басасы килә. Шул ук вакытта күңелне борчыган сораулар да кала бирә. Бүгенге сәхифәбезне дә укучыларыбызны кызыксындырган сорауларга җавап бирүгә багышларга булдык.

Аларга «Казан нуры» мәчете имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт МӨХЛИСОВ җавап бирде.

:: Күптән түгел каенанам мәрхүм булды. Йоласына туры китереп җирләдек. Тик менә бер нәрсәне белеп бетермибез икән. Аның кырыгын кайсы көннән исәплисе? Үлгән көненнәнме? Җирләнгән көненнәнме?

– Күмгән көненнән санала. Коръән ашын берәр көн алдан яки соңрак уздыруның да бернинди куркынычы юк. Сүз уңаеннан шунысын да искәртәсем килә: мәрхүмнең өчесен, җидесен, кырыгын уздыру – күбрәк гореф-гадәт ул. Шәригатебездә конкрет шул вакытта аш уздырырга кирәк, дигән таләп юк. Мөмкинлегә булса, кеше аны уздыра, мөмкинлеге булмыйча, уздырмаса да, гөнаһлы булмый.

:: Бала тугач, аның чәчен алмасаң ярыймы? Алсаң, ул чәчне ни эшләтергә? Истәлек итеп сакларга ярыймы?

– Бала тугач, аның чәчен алу – сөннәт гамәл. Алсаң – саваплы, алмасаң, бик зур гөнаһ түгел. Ләкин сабыйның чәчен алу хәерлерәк. Чөнки баланың чәче тагын да яхшырак үсә башлый. Күзләре дә яхшырак күрә дигән фикер дә яши. Баланың беренче алынган чәчен күмеп куюдан да яхшысы юк. Саклансаң, ул чит кешеләр кулына эләгеп, сихер ясаулары мөмкин.

:: Мин сатучы булып эшлим. Исерек ирләр акча сорап килә. Ләкин мин куып җибәрәм. Саранлыктан түгел, эшләмичә, акча теләнеп йөрүләренә ачуым килә. Мин дөрес эшлимме? Болай эшләп гөнаһлы булмыйммы?

– Әгәр без аларның акчаны аракы алырга тотуын төгәл белсәк, андый очракта акча бирү рөхсәт ителми. Әгәр алар бу акчаны ашарга алырга сораса, акчаны бирергә кирәк. Аракы алырга акча бирәбез икән, алар да, без дә гөнаһлы булабыз. Шуңа күрә сезнең очракта куып җибәрүегез хәерлерәк.

:: Намаз укымаучы кеше мөһим эш алдыннан теләге кабул булсын өчен генә тәһәҗҗуд намазы укыса, бу икейөзлелек, гөнаһ саналамы?

Гыйнвар аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Дүш	05:53	08:13	13:33	15:20	17:18
2	Сиш	05:53	08:12	13:34	15:21	17:19
3	Чәрш	05:53	08:12	13:35	15:23	17:20
4	Пән	05:52	08:12	13:36	15:24	17:21
5	Җом	05:52	08:11	13:38	15:25	17:22
6	Шим	05:52	08:11	13:39	15:27	17:23
7	Якш	05:52	08:10	13:40	15:28	17:24
8	Дүш	05:52	08:10	13:42	15:30	17:26
9	Сиш	05:51	08:09	13:43	15:31	17:27
10	Чәрш	05:51	08:08	13:45	15:33	17:28
11	Пән	05:50	08:07	13:46	15:34	17:29
12	Җом	05:50	08:06	13:48	15:36	17:31
13	Шим	05:49	08:06	13:49	15:38	17:32
14	Якш	05:49	08:05	13:51	15:40	17:34
15	Дүш	05:48	08:03	13:52	15:41	17:35
16	Сиш	05:47	08:02	13:54	15:43	17:36
17	Чәрш	05:46	08:01	13:56	15:45	17:38
18	Пән	05:46	08:00	13:58	15:47	17:39
19	Җом	05:45	07:59	13:59	15:49	17:41
20	Шим	05:44	07:57	14:01	15:51	17:43
21	Якш	05:43	07:56	14:03	15:53	17:44
22	Дүш	05:42	07:55	14:05	15:55	17:46
23	Сиш	05:41	07:53	14:07	15:57	17:47
24	Чәрш	05:40	07:52	14:09	15:59	17:49
25	Пән	05:39	07:50	14:10	16:01	17:51
26	Җом	05:37	07:48	14:12	16:03	17:52
27	Шим	05:36	07:47	14:14	16:05	17:54
28	Якш	05:35	07:45	14:16	16:07	17:56
29	Дүш	05:34	07:43	14:18	16:09	17:58
30	Сиш	05:32	07:42	14:20	16:11	17:59
31	Чәрш	05:31	07:40	14:22	16:14	18:01

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

islam.ru

– Теләгең кабул булсын өчен генә тәһәҗҗуд намазы укуның бер гөнаһы да юк. Ләкин намазны да укырга кирәк. Кызганыч, без Аллаһы Тәгаләне күбрәк үзебезгә кирәк вакытта, авыр чакта искә төшерәбез. Ләкин теләгән теләгебез тормышка ашса, Аллаһка шөкер дип, «Шөкер» намазын, башка намазларны да укырга кирәк. Пәйгамбәребезнең хәдисләреннән аңлашылганча, әгәр без Аллаһы Тәгаләне үзебезгә рәхәт, җиңел вакытта искә алсак, Аллаһы Тәгалә безне авырлык, кыенлык килгән вакытта искә алачак.

:: Авылга кайткач, 1,9 яшьлек улым белән зиратка кергән идем. «Бала белән керергә ярамый», – дип кисәтү ясадылар. Балаларга зиратка керергә ярамыймыни?

– Бала белән зиратка керергә ярый. Моны кем тыйган? «Ярамый, ник кердегез, бу – гөнаһ», – дип әйтүче дәлилен дә китерсен. Әгәр хатын-кызның күрем вакыты түгел икән, баласы белән зиратка кереп, дога кылып чыгуның бер гөнаһы да юк. Бу тәрбия ягыннан да мөһим адым бит. Бала да зиратка йөрергә, мәрхүмнәр рухына дога кылырга кирәклеген күреп, белеп үсә.

:: Өй каршындагы чыршы бик нык үсте. Багана чыбыкларына тиеп тора. Өй каршындагы чыршыны киссәң, нигезгә кайгы килә, йорттагы ир заты үлә, диләр. Бу чынлап та шулаймы икән? Безгә ни эшләргә?

– Дөресен генә әйткәндә, агачлар Аллаһы Тәгаләне искә алып, зекер әйтеп торалар. Ләкин әгәр бу агач комачаулый икән, аны кисәргә кирәк. Моның бернинди зыяны да юк. Нигезгә кайгы килә, кеше үлә дигән сүзләр исә – хорафат кына. Без, мөселманнар, тәкъдиргә ышанабыз. Аллаһы Тәгалә нәрсә насыйп иткән, нәрсә язган, шул була. Агач кисү аңа бәйле түгел.

:: Яңа елда бер-береңә ел символы төшкән магнит, ашъяулык ише әйберләр бүләк итсәң ярыймы?

– Бу – четерекле мәсьәлә. Без, мөселманнар, яңа елны – яңа көн, яңа ел исәбе, яңа календарь башлану итеп карыйбыз. Аллаһы Тәгаләдән, хәерле еллар булса иде, саулык-сәламәтлек, изгелекләр белән үткәрергә язса иде, дип сорыйбыз. Бу бәйрәм чын мөселман бәйрәме түгел. Шуңа күрә үзебезнең мөселман бәйрәмнәрен, Корбан, Ураза гаете кебек бәйрәмнәребезне, башка шундый истәлекле дини, милли бәйрәмнәрне билгеләп үтсәк иде. Үзебезнең бәйрәм бүләкләрен бирсәк, яхшырак була. Ел символы төшкән бүләкләр бирешмәү хәерлерәк.

:: Бүген берәү хәләл кибеттән краб таякчыклары ала. Бәясе – 160 сум, дигәч, борылып карарга мәҗбүр булдым. 30 сумлык шул краб таякчыгын, хәләл дип, нигә тапкыр арттырып саталар. «Ничек хәләл була ала соң ул?» – дип сорадым аптырап. Сатучы эндәшмәде. Сез ничек уйлыйсыз, краб таякчыклары хәләл була аламы? Бәлки, мин ялгышамдыр.

– Бу мәсьәләдә атаклы дин галимнәре арасында да төрле фикер яши. Кайбер галимнәр мөселманнарга краб таякчыгы ашарга ярый, икенчеләре, ярамый, дип саный. Краб таякчыкларының күбесе балыктан ясала. Кайберләренә, кызыл төс кертү өчен, кармин дигән матдә кушыла. Ул бөҗәкләрдән алына. Менә шул кармин кушылмаган краб таякчыгын хәләл дип әйтәләр. Бу очракта кеше үзе карый: әгәр Аллаһы Тәгаләдән курка икән, ул шикле ризыкны алмый, хәләлне алырга тырыша. Яшерен-батырын түгел, күп кенә сатучылар, хәләл дип, ризык бәясен икеләтә-өчләтә арттыра. Болай эшләмәсеннәр иде. Әгәр артык кыйбатка сатсаң, кешенең хәләлгә акчасы җитмичә, хәрамга кереп китәргә мөмкин.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

ӘНӘ, ДӨЯ ҺӘМ БАШКАСЫ...

Яңа ел – бүләкләргә бай бәйрәмнәрнең берсе. Бу юлы без сәхифәбез кунакларыннан иң истә калган бүләкләре турында сораштык. Нинди сәер бүләкләр алганнары бар икән? Бүләк бирергә яраталармы, әллә алыргамы?

Аннан-моннан: ел йомгаклары

2023 елда татар эстрадасында, социаль челтәрләрдә «шау-шу»лы нинди вакыйгалар булды?Ниләр булмый калды? Шуларны барладык.

Өйләнешүчеләр

> Җырчылар Винарис Ильегет белән Лилия Хәмитова.
> Җырчылар Ришат Төхвәтуллин белән Алия Карачурина.
> Баянчы Ильяс Шәрипов һәм сөйгәне Гөлшаһидә.
> Җырчы Гөлназ Батталова һәм сөйгәне Алекс.
> Җырчы Ильвира Хамматова һәм сөйгәне Равил.

Чак кына аерылышмый калучылар

> Ришат Фазлыйәхмәтов белән Эльмира «Тәтишка».
> Айгөл һәм Ришат Шәйхетдиновлар.

Бәби алып кайтучылар

> Җырчы Чәчкә.
> Алып баручы Зөлфия Шәмсуарова һәм актер Раил Шәмсуаров.
> Блогер Гүзәл Хөснетдинова.
> Җырчы Гөлназ Батталова.
> Блогер Рәмис Гыйльметдинов һәм тормыш иптәше Гүзәл.
> Салават Фәтхетдиновның улы Рөстәм һәм килене Рузия.
> Җырчы Айсылу Габдинова.

Сәхнәгә «кайтучылар»

> Альберт Вәлиуллин.
> Илнар Сәйфиев.
> Шәкүр.
> Лилия Хәмитова.
> «Айфара».

Ел шау-шуы

Дубайга күченеп, путевкалар сатып, мошенниклыкта гаепләнгән блогерлар Илусә һәм Рушан Миңнегалиевларга җинаять эше ачылу.

«Каз алып килсеннәр иде...»

Рәхмәт әйтеп, шкаф өстенә алып куярлык булмасын. Җырчы **Ләйсән Гыймаева** бүләкләрне әнә шундый кагыйдәгә таянып сайлый. «Үзенчәлекле булудан бигрәк, файдалы булсын. Әйтик, бизәнү әйберләре (ә алар гел кирәк), сөлгеләр, йомшак җылы оекбашлар... Үзем кабул иткән, бик истә калган бүләкләрдән фотолар тупланган матур, каты тышлы альбомнарны атар идем. Бик кирәкле дә, истәлекле дә бүләк», – ди ул. Кешедән бүләк көтмәсә дә, бер теләге бар икән. «Кунакка күчтәнәч кыстырып килү гадәте бар бит инде. Менә шундый чакта баллы ризык түгел, казмы, үрдәкме – кыскасы, ит ризыгы алып килсеннәр иде *(көлә)*. Бик сөенер идем шуңа», – дип сөйләде Ләйсән Гыймаева.



«Ни сөенергә, ни еларга белмим»

Юморист **Сирин Бәйрәмовка** аның өчен иң кадерле һәм иң истә калган бүләкне балачакта биргәннәр. «Мин бәләкәй чакта без «малосемейка»да яши идек. Әтинең милициядә эшләгән вакыты. Аңа эшеннән Яңа ел күчтәнәче бирәләр иде. Пакетка тутырылган бер мандарин, бер алма, нindидер кәнфитләр...

Без йоклаганда гына кайта торган әти ул бүләкне җеп белән аякларыбызга бәйләп куя иде. Имеш, аны куян яки Кыш бабай алып килгән. 2–3 нче сыйныфларда укыганда, бер кызык хәл булды. Әти бүләк бәйләнгән җепне мин йоклый торган раскладушканың «аягы»на да бәйләгән булса кирәк, торам дигәндә, маңгаем белән идәнгә «кадалдым». Ни сөенергә, ни еларга белмим... Менә иң истә калган бүләгем шул булды. Ул чакта бит юктан да күңел була торган иде, заманалар хәзергедәй рәхәт булмагангадыр инде...» – дип искә алды ул. Хәзер исә ул көймә моторы турында хыяллана икән. «Кайчагында акча җитми, акча булганда, башка нәрсәгә тотыла. Шуны берәрсе бүләк итсә, нык сөенер идем», – ди Сирин.

«Кирәк булсын ул»

Скрипкачы **Динә Закирова** бүләкләрнең креативлыгына түгел, кирәкле булу-булмавына игътибар итә. «Бүләккә килгәндә, мин – бик «практичный» кеше: кирәк әйберләр генә бүләк итәргә яратам. Шулай ук мине яхшы белгән якыннарым да кирәкле әйберләр генә бүләк итәргә тырыша. Алай креатив бүләкләр истә түгел үзе...» – диде ул безгә. Сүзләрен бер мисал белән раслады. «Мин җәй көнне туганмын. Гадәттә, андый кешеләргә чәчәк бәйләмнәре бүләк итәләр. Ә миңа якыннарым озак яши торган гөлләр бүләк итә», – ди Динә Закирова. Ә бүләкне алу күңеллерәкме икән аңа, бирүме? «Күбрәк үзем бүләкләр бирергә яратам», – диде ул.

«Сиздермәде шуны...»

Блогер **Ринат Галиәхмәтовка** («Татар Малай») бүләк бирер өчен сәбәп тә кирәкми икән. «Бүләк биргәндә, миңа кешенең нинди хисләр кичерүе мөһим. Бүләккә чын күңелдән сөенүчеләрне гел сөендереп торасы килә», – ди Ринат. Иң креатив бүләкне аңа узган ел тормыш иптәше Илүзә ясаган. «Узган ел туган көнемдә, миңа әйтмичә, бер йортка барлык дус-туганнарымны җыйган иде ул. Гел сиздермәде шуны! Шуңа да бик зур сюрприз булды ул минем өчен. Күпләр миңа акча бүләк итәргә ярата. Югыйсә, бар нәрсәм дә бар, акча да кирәкми, дисәм дә. Дөресен генә әйткәндә, акча урынына нинди дә булса яңа, көтелмәгәнрәк, кызыклы бүләк кабул итәр идем мин», – дип сөйләде ул безгә.

3 гыйнвар | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН
14.40, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 00.35 «ТРИ МУШКЕТЁРА» 12+
08.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
11.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Синең өчен сөюләрем» 16+
14.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
16.05 «Шаян»да Үзгәреш җиле» 0+
17.50 «Соотечественники» 12+
18.20 «КАЗАНГА КАЗАНДА» 16+
19.30 «Яңа Гасыр»да – Яңа ел!» 16+
22.50 «МАМЫ» 16+
02.25 «Секреты татарской кухни» 16+
02.50, 03.40 «Каравай» 6+
03.15 «Музыкальный майдан» 16+
04.05 «Гаилә учагы» 16+
04.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 19.30, 02.55 «Татарлар» 12+
06.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.25 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
08.30 «Гаилә учагы» 16+
09.05 «Яңа елда минем гаиләм» 16+
10.00 «АЛМАШ» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
13.00 Т.Миңнуллин. «Йөрәк маем». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
16.00 «Кәмит Җавит» 16+
17.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
19.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
20.00 «Бүләк булып калсын җырларым» 16+
22.30 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.15 «КУНАК АШЫ – КАРА-КАРШЫ, ЯКИ КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2» 16+
03.20 Г.Исхакый. «Курчак туе». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
05.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

1 КАНАЛ
06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.30 «ОГОНЬ, ВОДА И... МЕДНЫЕ ТРУБЫ» 0+
08.00 «Доброе утро»
10.15 «Модный приговор» 0+
11.10 «Играем свадьбу!» 12+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.20 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
15.15 «Угадай мелодию» 12+
16.05 «КАЗАНОВА» 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Я люблю мою страну» 0+
19.25 «Сегодня вечером» 16+
21.00 «Время»
21.35 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ» 16+
23.25 «ДИАНА ДЕ ПУАТЬЕ» 16+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.10 «ДНЕВНИК СВЕКРОВИ» 12+
06.45 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ» 12+
08.40 «Утренняя почта»
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.55 «ПАЛЬМА» 6+
14.40, 21.05 Вести. Местное время
14.55 «Олег Газманов. 55 лет на сцене»
17.50 «Песни от всей души» 12+
21.20 «ТАЙНА ЛИЛИТ» 12+
01.30 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Лига героев» 12+
07.00, 10.05, 12.35, 17.40, 04.00 Новости 0+
07.05, 13.10, 17.45, 22.45 Все на Матч!
10.10 «Спорт Тоша» 0+
10.30 «Вираж» 12+
12.40 «Вид сверху» 12+
13.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Авангард» – «Салават Юлаев»
16.15 Прыжки на лыжах с трамплина. «Турне 4-х трамплинов»
18.55 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Спринт
20.45 Бильярд. «BetBoom Суперлига». 1/2 финала
23.15 «Команда мечты» 6+
00.50 Матч! Парад 6+
01.15 «География спорта» 12+
02.30 Художественная гимнастика. Небесная грация 6+
04.05 Футбол. Лига чемпионов. ПСЖ (Франция) – «Милан» (Италия) 6+

НТВ
05.15 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «ГАРАЖНЫЙ ПАПА» 12+
10.20 «Домисолька. Время чудес» 0+
12.15 «БАЛАБОЛ» 16+
19.30 «БИМ» 16+
22.40 Юбилейный концерт Ларисы Долиной 12+
01.15 «Секрет на миллион» 16+
02.10 «ОТСТЕГНИТЕ РЕМНИ» 16+

ДОМАШНИЙ
07.50 «МУЖЧИНА В МОЕЙ ГОЛОВЕ» 16+
10.25 «БОЛЬШЕ ЧЕМ ПРИКОСНОВЕНИЕ» 16+
15.00 «ДИТЯ РАЗДОРА» 16+
23.45 «МЕСТЬ И ЗАКОН» 16+
03.20 «СЕРДЦЕ РИТЫ» 16+

ЗВЕЗДА
07.15 «ГОРИ, ГОРИ, МОЯ ЗВЕЗДА» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15 «Код доступа» 12+
21.00 «КУБАНСКИЕ КАЗАКИ» 12+
23.10 «ЛЕТУЧАЯ МЫШЬ» 12+
01.40 «СВАДЬБА С ПРИДАНЫМ» 12+
03.35 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ» 16+

4 гыйнвар | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН
14.40, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 00.40 «ТРИ МУШКЕТЁРА» 12+
08.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 16+
11.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Нечкәбил-2023» 12+
14.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
16.05 «Соотечественники» 16+
16.30 «Яшик әле!» 12+
19.30 «Менә ул бәхет!» 12+
21.00 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 12+
23.00 «10 ДНЕЙ С САНТОЙ» 12+
02.25 «Секреты татарской кухни» 12+
02.50, 03.40 «Каравай» 6+
03.15 «Музыкальный майдан» 16+
04.05 « Гаилә учагы» 16+
04.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 19.30, 00.05 «Татарлар» 12+
06.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.20, 19.50 «Яңа Гасыр»да – Яңа ел!» 6+
08.40 «Гаилә учагы» 16+
09.10 «Яңа елда минем гаиләм» 16+
10.00 «АЛМАШ» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
13.00 «Яшик әле!» 16+
16.05 «Кәмит Җавит» 16+
17.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
19.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
23.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
00.30 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН» 16+
04.00 Н. Исәнбәт. «Миркәй белән Айсылу». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
05.50 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

1 КАНАЛ
06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.40 «ЗОЛОТЫЕ РОГА» 0+
08.00 «Доброе утро»
10.15 «Модный приговор» 0+
11.10 «Играем свадьбу!» 12+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.20 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
15.15 «Угадай мелодию» 12+
16.05 «КАЗАНОВА» 16+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Я люблю мою страну» 0+
19.25 «Сегодня вечером» 16+
21.00 «Время»
21.35 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ» 16+
23.25 «ДИАНА ДЕ ПУАТЬЕ» 16+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.10 «ДНЕВНИК СВЕКРОВИ» 12+
06.45 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ» 12+
08.40 «Утренняя почта»
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.15, 20.00 Вести
11.35 «ХИТРОВКА. ЗНАК ЧЕТЫРЁХ» 12+
14.40, 21.05 Вести. Местное время
14.55 Большой юбилейный концерт Николая Баскова
17.50 «Песни от всей души» 12+
21.20 «ТАЙНА ЛИЛИТ» 12+
01.30 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Лига героев» 12+
07.00, 10.05, 12.35, 14.50, 04.00 Новости
07.05, 14.15, 16.55, 19.45, 22.30 Все на Матч!
10.10 «Спорт Тоша» 0+
10.30 «Я – ЗЛАТАН» 12+
12.40 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Гонка преследования. Женщины
13.45 «Большой хоккей» 12+
14.55 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Гонка преследования. Мужчины
15.50 «Эпоха Романцева» 12+
17.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Нефтехимик» (Нижнекамск) – «Лада» (Тольятти)
20.30 Бильярд. «BetBoom Суперлига». 1/2 финала
23.15 «ВИРАЖ» 12+
01.15 «География спорта» 12+
02.30 Художественная гимнастика. Небесная грация 6+
04.05 Футбол. Лига чемпионов. «Копенгаген» (Дания) – «Манчестер Юнайтед» (Англия) 6+

НТВ
05.15 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «ЗИМНИЙ КРУИЗ» 16+
10.20 «Добрая волна» 0+
12.15 «БАЛАБОЛ» 16+
19.30 «БИМ» 16+
22.40 «Я не боюсь» 16+
00.55 «Секрет на миллион» 16+
02.00 «ОТСТЕГНИТЕ РЕМНИ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 Предсказания: 2024 16+
08.25 «ВОСПИТАНИЕ И ВЫГУЛ СОБАК И МУЖЧИН» 16+
10.40 «СЛУЧАЙНЫЕ ВСТРЕЧИ» 16+
15.00 «ЗЕРКАЛО ДЛЯ ОБОРОТНЯ» 16+
23.30 «ДАВАЙТЕ ПОЗНАКОМИМСЯ» 16+
01.30 «С ЧИСТОГО ЛИСТА» 16+
04.45 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
06.20 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА
07.15 «ДЕВУШКА С ГИТАРОЙ» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15 «Секретные материалы» 16+
21.00 «СЕМЬ НЯНЕК» 12+
22.30 «СОБАКА НА СЕНЕ» 12+
01.00 «ЛЕТУЧАЯ МЫШЬ» 12+
03.15 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ-2» 16+

5 гыйнвар | Җомга

ТАТАРСТАН
14.45, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 00.40 «ТРИ МУШКЕТЁРА» 12+
08.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 16+
11.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 16+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Восточный базар-2023» 12+
14.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
16.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
16.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Адмирал» 6+
19.30 «СӨЮЛӘРЕМ СИНЕ ХАК МИНЕМ» 16+
21.30 «Яңа татар җыры-3» 16+
23.20 «КОРОТКИЕ ВОЛНЫ» 16+
02.25 «Секреты татарской кухни» 12+
02.50 «Каравай» 6+
03.15 «В стране дружбы...» 12+
03.40 «Музыкальный майдан» 16+
04.05 «Гаилә учагы» 16+
04.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 19.30, 02.00 «Татарлар» 12+
06.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.20 «КАЗАНГА КАЗАНДА» 16+
08.40 «Гаилә учагы» 16+
09.10 «Яңа елда минем гаиләм» 16+
10.00 «АЛМАШ» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
13.00 «Кайт әйдә, Кыш бабай!» 6+
14.30 «Кайда сез, яшьлек елларым?» 16+
16.00 «Кәмит Җавит» 16+
17.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
20.00 «Восточный базар – Шәрык базары 2023» 12+
22.20 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.30 «ЫШАНАСЫ КИЛӘ» 16+
02.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 16+
05.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

1 КАНАЛ
06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.10 «ФРАНЦУЗ» 12+
08.00 «Доброе утро»
10.15 «Модный приговор» 0+
11.10 «Играем свадьбу!» 12+
12.15 «Поехали!» 12+
13.10 «Видели видео?» 0+
14.20 «Давай поженимся в Новый год!» 16+
15.15 «Угадай мелодию» 12+
16.05 «КАЗАНОВА» 16+
18.00 Вечерние новости
18.25 «Я люблю мою страну» 0+
19.40 «Поле чудес» 16+
21.00 «Время»
21.35 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ» 16+
23.25 «ДИАНА ДЕ ПУАТЬЕ» 16+
00.25 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1
05.10 «ДНЕВНИК СВЕКРОВИ» 12+
06.45 «МЕЖДУ НАМИ ГЛУБОКОЕ МОРЕ» 12+
08.40 «Утренняя почта»
09.20 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.45 «Измайловский парк» 16+
14.45, 21.05 Вести. Местное время
15.00 «Классная тема!»
17.50 «Песни от всей души» 12+
21.20 «ТАЙНА ЛИЛИТ» 12+
01.30 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Лига героев» 12+
07.00, 10.05, 12.25, 14.50, 04.00 Новости
07.05, 12.30, 19.45, 22.30 Все на Матч!
10.10 «Спорт Тоша» 0+
10.30 Биатлон. Альфа-Банк Кубок Содружества
14.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «ПАРМА» – «Зенит»
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Спартак» (Москва)
20.30 Бильярд. «BetBoom Суперлига»
23.15 «Я – ЗЛАТАН» 12+
01.15 «География спорта» 12+
02.30 Волейбол. Pari Суперлига. Мужчины. «Динамо» – «Нефтяник» 6+
04.05 Футбол. Лига чемпионов. «Севилья» – ПСВ 6+

НТВ
05.10 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20, 03.20 «НОЛЬ» 16+
10.20 «Белая трость» 12+
12.15 «БАЛАБОЛ» 16+
19.30 «БИМ» 16+
22.40 «Ани Лорак. Концерт в день рождения» 12+
00.45 «Секрет на миллион» 16+
01.45 «ЗИМНИЙ КРУИЗ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.40 «НЕ МОГУ СКАЗАТЬ «ПРОЩАЙ» 16+
08.20 «СЕРДЦЕ ЖЕНЩИНЫ» 16+
10.35 «КРЕСТЕЦКАЯ ВЫШИВКА» 16+
15.00 «ВЫДРА» 16+
23.25 «ТАРИФ НА ЛЮБОВЬ» 16+
01.10 «Любимый Новый год» 16+
04.30 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
06.10 «Домашняя кухня» 16+

ЗВЕЗДА
07.00 «КУБАНСКИЕ КАЗАКИ» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15 «Улика из прошлого» 16+
21.00 «НЕПОДДАЮЩИЕСЯ» 12+
22.35 «Здравствуйте, товарищи!» 16+
00.30 «СОЛОМЕННАЯ ШЛЯПКА» 12+
02.55 «РУССКИЕ АМАЗОНКИ-2» 16+

ЦЕНТРАЛЬНАЯ ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ КОМИССИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

27 декабря 2023 г. № 33/233

г. Казань

О передаче вакантного мандата депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва зарегистрированному кандидату из республиканского списка кандидатов, выдвинутого избирательным объединением «Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ», Шамсутдинову Раилю Рафаэлевичу

В связи с досрочным прекращением полномочий депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва Ганиева Ильшата Газимовича, избранного в составе республиканского списка кандидатов, выдвинутого избирательным объединением «Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ», в соответствии с частями 1.1 и 1.2 статьи 103 Избирательного кодекса Республики Татарстан, учитывая решение Президиума Регионального политического совета Татарстанского регионального отделения Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ» от 22 декабря 2023 года «О предложении Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан кандидатуры для замещения вакантного депутатского мандата депутата Государственного Совета Республики Татарстан», Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. Передать вакантный мандат депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва зарегистрированному кандидату в депутаты Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва из республиканского списка кандидатов, выдвинутого избирательным объединением «Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ», Шамсутдинову Раилю Рафаэлевичу (порядковый номер в республиканском списке кандидатов 49).

2. Опубликовать настоящее постановление в газетах «Республика Татарстан» и «Ватаным Татарстан».

Председатель Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан А.С. Кондратьев

Секретарь Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан Н.П. Борисова

ЦЕНТРАЛЬНАЯ ИЗБИРАТЕЛЬНАЯ КОМИССИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

27 декабря 2023 г. № 33/234

г. Казань

О регистрации депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва Шамсутдинова Раиля Рафаэлевича

На основании постановления Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан от 27 декабря 2023 года № 33/233 «О передаче вакантного мандата депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва зарегистрированному кандидату из республиканского списка кандидатов, выдвинутого избирательным объединением «Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ», Шамсутдинову Раилю Рафаэлевичу», в соответствии с частью 4 статьи 100, пунктом 7 части 5 статьи 103 Избирательного кодекса Республики Татарстан Центральная избирательная комиссия Республики Татарстан ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. Зарегистрировать депутата Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва Шамсутдинова Раиля Рафаэлевича.

2. Выдать зарегистрированному депутату Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва удостоверение об избрании.

3. Исключить зарегистрированного кандидата в депутаты Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва Шамсутдинова Раиля Рафаэлевича (порядковый номер в республиканском списке кандидатов 49) из допущенного к распределению мандатов депутатов Государственного Совета Республики Татарстан шестого созыва республиканского списка кандидатов, выдвинутого избирательным объединением «Татарстанское региональное отделение Всероссийской политической партии «ЕДИНАЯ РОССИЯ».

4. Опубликовать настоящее постановление в газетах «Республика Татарстан» и «Ватаным Татарстан».

Председатель Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан А.С. Кондратьев

Секретарь Центральной избирательной комиссии Республики Татарстан Н.П. Борисова

6 гыйнвар | Шимбә

ТАТАРСТАН

20.45 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «ТРИ МУШКЕТЁРА» 12+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00, 03.30 «Гаилә учагы» 16+
09.30 «Видеоспорт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Музыкальный майдан» 16+
11.30 «Бүләк булып калсын җырларым. Ринат Мөслимов» 16+
15.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
17.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
18.00 «Кәмит Җәвит» 16+
19.00 «Халкым минем…» 12+
19.30 Новости в субботу 16+
20.00 «Тылсымлы бәйрәм мизгелләре» 12+
20.30, 04.50 «Җырлыйк әле!» 12+
21.30 Новости в субботу 16+
22.00 «МОДЕЛЬ СЧАСТЛИВОЙ ЖИЗНИ» 16+
23.50 Рождество Христово 0+
01.30 «Путь» 16+
02.00 «Каравай» 6+
02.25 «Секреты татарской кухни» 12+
02.50 «В стране дружбы…» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
09.00 «Сөйләшергә вакыт» 16+
10.00 «Кайнар хит» 16+
11.00 «Мәңгелек… Ирек… Хисләр…» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
13.00 «Менә ул, бәхет!» 16+
15.00 «Сиңа Миннән Сәлам» 16+
17.00 «Ялт-йолт» 16+
20.15 «Фәрештә түгел» 16+
22.30 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
23.20 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА» 16+
03.30 «Казан» бию ансамбле концерты 6+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.35 «БЕДНАЯ САША» 12+
08.30 «МОЯ ЛЮБОВЬ» 12+
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.15 «Модный приговор» 0+
11.10 «Играем свадьбу!» 12+
12.15 «ФИНИСТ – ЯСНЫЙ СОКОЛ» 0+
13.45 «ТАЙНА» 0+
15.20 «Иисус. Земной путь» 0+
16.15 «Рождество в России. Традиции праздника» 0+
17.10 «Угадай мелодию» 12+
18.00 Вечерние новости
18.20 «Эксклюзив» 16+
19.15 Шоу Ильи Авербуха 0+
21.00 «Время»
21.35 «Сегодня вечером» 16+
23.00 Рождество Христово
01.15 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

06.05 «ПАЛЬМА» 6+
08.15 «ГАРДЕМАРИНЫ, ВПЕРЁД!» 0+
11.00, 20.00 Вести
14.05 «ГАРДЕМАРИНЫ 1787. МИР» 12+
16.05 «ГАРДЕМАРИНЫ 1787. ВОЙНА» 12+
17.50 «Гардемарины-2024» 12+
20.45 Вести. Местное время
21.00 «НЕПОСЛУШНИК 2. ВСПОМНИТЬ ВСЁ!» 12+
23.00 Рождество Христово
03.10 «СНЕГ НА ГОЛОВУ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Лига героев» 12+
07.00, 10.05, 12.25, 04.00 Новости
07.05, 12.30, 14.55, 17.05, 22.00, 01.30 Все на Матч!
10.10 «Команда МАТЧ» 0+
10.30 Биатлон. Альфа-Банк Кубок Содружества. Гонка преследования. Мужчины
11.55 «География спорта» 12+
13.35 Биатлон. Альфа-Банк Кубок Содружества. Гонка преследования. Женщины
15.25 Гандбол. OLIMPBET Кубок дружбы. Мужчины. Россия – Иран
17.20 Лыжные гонки. «Тур де Ски». Масс-старт. Мужчины
18.10 Футбол. Кубок Испании. 1/16 финала. «Луго» – «Атлетико»
19.55 Футбол. Кубок Испании. 1/16 финала. «Эльче» – «Жирона»
22.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Сассуоло» – «Фиорентина»
00.45 Футбол. Кубок Испании. 1/16 финала. «Арандина» – «Реал» (Мадрид)
02.10 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Руна» (Москва) – УНИКС (Казань) 6+
04.05 Футбол. Лига чемпионов. «Бенфика» (Португалия) – «Интер» (Италия) 6+

НТВ

05.15 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «ВЕТЕР СЕВЕРНЫЙ» 16+
10.20 «Снегурочка» 0+
12.15 «БАЛАБОЛ» 16+
19.30 «БИМ» 16+
22.40 «Хиты 80-90х. Дискотека» 12+
00.20 «НАСТОЯТЕЛЬ» 16+
02.00 «НАСТОЯТЕЛЬ-2» 16+
03.30 «ВЕТЕР СЕВЕРНЫЙ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «ДАВАЙТЕ ПОЗНАКОМИМСЯ» 16+
08.25 «БЕЗОТЦОВЩИНА» 16+
10.30 «ПЕРВОКУРСНИЦА» 16+
14.40 «С ДНЁМ РОЖДЕНИЯ, ВИКА!» 16+
19.00 «ВОРОН» 16+
22.45 «ВЕЧЕРА НА ХУТОРЕ БЛИЗ ДИКАНЬКИ» 16+
00.15 «Предсказания: 2024» 16+
03.45 «Гадаю-ворожу» 16+
05.20 «Новый год по-домашнему» 16+

ЗВЕЗДА

06.40 «ДЕЛО БЫЛО В ПЕНЬКОВЕ» 12+
08.30 «В знании – сила, в красоте – спасение, в служении – судьба» 16+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15 «СССР. Знак качества» 12+
21.00 «НЕОКОНЧЕННАЯ ПОВЕСТЬ» 12+
23.00 «ОТЧИЙ ДОМ» 12+
00.45 «История русских крепостей. Соловки. На страже русского севера» 16+
02.05 «Крест Иоанна Кронштадтского» 16+
02.30 «Москва фронту» 16+
02.50 «СПАС ПОД БЕРЕЗАМИ» 16+

7 гыйнвар | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

8.00 Местное время. Воскресенье
20.45 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 00.40 «ТРИ МУШКЕТЁРА» 12+
07.00 «ГОСПОЖА МЕТЕЛИЦА» 0+
08.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 16+
10.30 Республиканская новогодняя елка 0+
11.30 «Кызган казан» 16+
12.00 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
13.00 «Ком сәгате» 16+
14.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
16.45 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Автомобилист» 6+
19.30 «Видеоспорт» 16+
20.00 «Эльмир Низамов һәм дуслар» 16+
22.00 «ЛЕКАРЬ. УЧЕНИК АВИЦЕННЫ» 16+
02.25 «Секреты татарской кухни» 12+
02.50 «Путь» 16+
03.05 «Реквизиты былой суеты» 6+
03.20 «Музыкальный майдан» 16+
03.45 «Каравай» 6+
04.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
05.0 «Гаилә учагы» 16+
05.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
07.00 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
10.00 «ҮКСЕЗЛӘР» 16+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
13.05 «Хыялга омтылыш» 6+
14.05 «ШАЯН»да үзгәреш җиле» 6+
16.00 «Кәмит Җәвит» 16+
17.00 Р.Ваһапов исемендәге XX Халыкара татар җыры фестиваленең гала-концерты 16+
19.00 «Ком сәгате» 16+
19.50 Жан-Батист Мольер. «Дон Жуан». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
22.20 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+
23.10 Т.Миңнуллин. «Шулай булды шул». Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
01.05 «Яңа елны ТНВ белән бергә каршылыйк!» 6+
03.25 «ҮКСЕЗЛӘР» 16+

1 КАНАЛ

06.00, 10.00, 12.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион» 12+
09.40 «Непутевые заметки» 12+
10.15 «Играем свадьбу!» 12+
11.10 «ЗОЛУШКА» 0+
13.05 «СТАРИК ХОТТАБЫЧ» 0+
14.40 «ЁЛКИ-ИГОЛКИ» 12+
16.40 «Рождество с Григорием Лепсом» 12+
18.00 Вечерние новости
19.10 «Лучше всех!» 0+
21.00 «Время»
21.35 «БАБА МОРОЗ И ТАЙНА НОВОГО ГОДА» 12+
23.30 Концерт Полины Гагариной 12+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ 16+

РОССИЯ 1

04.45 «РАЗВОДА НЕ БУДЕТ» 12+
06.20 «МЕЖДУ НАМИ НЕБО» 12+
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному»
11.00, 20.00 Вести
11.55 Рождественское интервью Святейшего Патриарха Кирилла
12.20 «РУССКИЙ КРЕСТ» 12+
13.30 «Отец Иоанн» 12+
14.25 «НЕПОСЛУШНИК» 12+
16.35 «НЕПОСЛУШНИК 2. ВСПОМНИТЬ ВСЁ!» 12+
18.40 «Нежность твоя»
20.45 Вести. Местное время
21.00 «ВАША ТЁТЯ ЛЮСИ» 12+
01.15 «ВЕРНОСТЬ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Тайский бокс. Muay Thai Factory. Артём Вахитов против Паскаля Тауре
07.00, 10.05, 12.25, 16.50, 19.50, 04.00 Новости
07.05, 12.30, 19.00, 22.00, 01.00 Все на Матч!
10.10 «Команда МАТЧ» 0+
10.30 Биатлон. Альфа-Банк Кубок Содружества. Масс-старт. Мужчины
11.50 Биатлон с Дмитрием Губерниевым
13.35 Биатлон. Альфа-Банк Кубок Содружества. Масс-старт. Женщины
15.10 Гандбол. OLIMPBET Кубок дружбы. Мужчины. Россия – Беларусь
16.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Торино» – «Наполи»
19.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Салернитана» – «Ювентус»
22.55 Футбол. Кубок Испании. 1/16 финала. «Малага» – «Реал Сосьедад»
01.40 Матч! Парад 6+
02.10 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Автодор» (Саратов) – «Пари Нижний Новгород» 6+
04.05 Футбол. Лига чемпионов. «Боруссия» (Дортмунд, Германия) – ПСЖ (Франция) 6+

НТВ

05.15 «Таинственная Россия» 16+
06.00 «НАСТОЯТЕЛЬ» 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Рождественская песенка года» 0+
12.15 «БАЛАБОЛ» 16+
19.30 «БИМ» 16+
22.40 Юбилейный концерт Валерии 12+
01.05 «Секрет на миллион» 16+
02.05 «ПРОТИВ ВСЕХ ПРАВИЛ» 16+
03.45 «АЛМАЗ В ШОКОЛАДЕ» 12+

ДОМАШНИЙ

07.00 «ВЕЧЕРА НА ХУТОРЕ БЛИЗ ДИКАНЬКИ» 16+
08.20 «ПРИЕЗЖАЯ» 16+
10.30 «УРОКИ СЧАСТЬЯ» 16+
14.40 «ЖЕНУ ВЫЗЫВАЛИ?» 16+
19.00 «ВОРОН» 16+
22.45 «БЕЗОТЦОВЩИНА» 16+
00.45 «МОЛОДАЯ ЖЕНА» 16+
02.30 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+

ЗВЕЗДА

07.10 «НЕОКОНЧЕННАЯ ПОВЕСТЬ» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 13.15, 19.15 «Не факт!» 12+
21.00 «ДЕЛО БЫЛО В ПЕНЬКОВЕ» 12+
23.05 «ПОКРОВСКИЕ ВОРОТА» 12+
01.30 «НЕПОДДАЮЩИЕСЯ» 12+
02.50 «СПАС ПОД БЕРЕЗАМИ» 16+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 1 гыйнвар

06.00 Татарстан радиосының Яңа ел сәламе
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
07.00 Вести радио России
07.10 «Исәнме, Яңа ел!»
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
08.10 «Аклык иле»
11.10 «Чыршы әйләнәсендә»
11.25 Концерт
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 «Киләчәккә билет»
18.10 Эстрада музыкасы концерты

Сишәмбе, 2 гыйнвар

06.00 «Яңа көн»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.45 «Актуальное интервью»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.10 Дания Гайнетдинова әсәрләреннән әдәби-музыкаль композиция
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 Антуан де Сент-Экзюпери. «Нәни принц»
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Лирик концерт

Чәршәмбе, 3 гыйнвар

06.00 «Яңа көн»
06.15 «Музыкаль мизгелләр»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
7.10 «2024 ел – Россия Федерациясендә Гаилә елы»
08.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10 Популяр музыка концерты
11.40 Прокуратура разъясняет
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшлек аланы»
18.10 «Шүрәле» балетыннан фрагментлар
18.45 Яңалыклар

Пәнҗешәмбе, 4 гыйнвар

06.00 «Новый день»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Беседа на тему: «Здоровый образ жизни»
8.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10 Вакыйф Нуриев. «Мәһдиев һәм… » Радиоспектакль
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевнең якты истәлегенә
18.10 Разил Вәлиев шигырьләреннән һәм аларга иҗат ителгән җырлардан әдәби-музыкаль композиция
18.45 Яңалыклар

Җомга, 5 гыйнвар

06.00 «Иртәнге нур»
06.25 «Музыкаль мизгелләр»
06.50, 07.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
07.00 Вести радио России
07.10 Россиядә Гаилә елы башлану уңаеннан әхлакый темага әңгәмә
8.00, 12.00, 14.00, 16.00, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10 «Акбай һәм Кыш бабай». Г. Камал ис. ТДАТ спектакле
13.10 «Татарстан дулкынында»
18.10 Лирик концерт
18.45 Яңалыклар

Шимбә, 6 гыйнвар

08.10 Әдәби-музыкаль композиция
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Әкият иленә сәяхәт»
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Концерт. Халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»

Якшәмбе, 7 гыйнвар

08.10 «Между Волгой и Уралом»
09.00, 11.00, 12.00, 14.00, 16.00, 17.00 Трансляция радио России
10.10 Зәки Зәйнуллин. «Майор Гаврилов». Моноспектакль
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Изге Раштуа»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Бәйрәм концерты
16.10 «Яңа ел төнендә, лифт төбендә». Радиотамаша

Белдеру

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ ПО СОГЛАСОВАНИЮ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Осиповым Алексеем Федоровичем (г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524, СНИЛС 047-159-072-63, квалификационный аттестат 16-15-843; реестр кадастровых инженеров № 36006; СРО АКИ «Поволжье» № 1145 протокол № 18/2016 от 22.11.2016 г.) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:16:180301:106, расположенного по адресу: Республика Татарстан (Татарстан), Высокогорский р-н, Чепчуговское с/п, д. Старые Бирюли, ул. Дачная, д. 6, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границы земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Валеев Дамир Хамитович, Российская Федерация, 420073, Республика Татарстан (Татарстан), г. Казань, ул. Толбухина, д. 7, кв. 59, тел.: +7 9033054486 (доверенное лицо).

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится по адресу: Республика Татарстан (Татарстан), Высокогорский р-н, Чепчуговское с/п, д. Старые Бирюли, ул. Дачная, д. 6 29 января 2024 г. в 10 часов 00 минут.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524 (предварительно позвонить).

Обоснованные возражения относительно местоположения границ, содержащихся в проекте межевого плана, и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 29 декабря 2023 г. по 28 января 2024 г.
по адресу: г. Казань, ул. Журналистов, д. 30, кв. 108, e-mail: geodezy@rambler.ru, тел.: +7 9600559524 (предварительно позвонить).

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ:
16:16:180301:105 Российская Федерация, Республика Татарстан, Высокогорский муниципальный район, Чепчуговское сельское поселение, д. Старые Бирюли, ул. Дачная, з/у 4;
16:16:180301:546 Российская Федерация, Республика Татарстан, Высокогорский муниципальный район, Чепчуговское сельское поселение, д. Старые Бирюли, ул. Садовая, з/у 9 А.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок (часть 12 статьи 39, часть 2 статьи 40 Федерального закона от 24 июля 2007 г. № 221-ФЗ «О кадастровой деятельности»).

КӘБИСӘ

АРТЫК БЕР КӨННӘН НӘРСӘ КӨТӘРГӘ?

«Берүк кәбисә елда өйләнешә күрмәгез». «Кәбисә елда эш башлама». Дүрт елга бер килә торган кәбисә турындагы ышанулар, юрауларны электән ишетеп беләбез. Гомумән, андый елга сагаеп караучылар шактый. Чираттагы 366 көннән – 2024 елдан куркырга кирәкме? Бу кәбисә ел безгәниләр вәгъдә итә?

«Ышанмыйча мөмкин түгел...»

«2008 елның кышында – әниебез, җәендә әтиебез арабыздан китеп барды. Дүрт елдан абыебыз йоклаган җиреннән уянмады...» Казанда яшәүче ике бала әнисе Чулпан Хәйруллина үткәндә калган кәбисә елларны күз яшьләре белән искә ала.

– 2016 елны начар булды дип әйтә алмыйм. Хыялда йөрткән машинамны алдым, кредитларымны капладым, хәйран гына акча эшли башладым. Ә менә 2020 ел тагын аяктан ега язды. Ирем, коронавирус йоктырып, арты ел үлем белән көрәште, – ди ул. – Киләсе ел нинди булыр – әйтү кыен. Дөресен генә әйткәндә, сынаулар кәбисә ел булу-булмауга карамый, күрәчәктер ул. Элек ышана идем, хәзер инде яңа елны яхшы ният белән көтәм. Бар да ниятләгәнчә булачак.

Ә кәбисә елда туучылар бу хакта ни уйлый икән? 23 яшьлек Казан егете Риназ Сәмигуллинның нинди елда туыуна артык исе китми.

– 23 елда бер начарлыгы да тигәне юк. Минем өчен кәбисә ел өстәмә бер көн дигәнне генә аңлата. Өлкәннәрнең: «Кәбисә елда туй итәргә ярамый», – дигәненә дә ышанмыйм. Бар нәрсә дә үзебездән тора, – ди Риназ.

Актаныштан Сәмигуллиннар гаиләсе икенче балаларын 2016 елның март аенда туар дип көткән. Ләкин кызлары 29 февраль иртәсендә дөньяга аваз сала.

– Ашыкты кызыбыз *(көлә)*. Башта бераз борчылган идек инде, әбиләребезнең, әниләребезнең кәбисә ел турында сөйләгәннәре хәттә куркырга мәҗбүр итте. Аллага шөкер, туган көнен дүрт елга бер мәртәбә 29 февральдә уздырудан тыш, башка бер проблема да юк, – дип сөйләде Ләйсән Сәмигуллина.

29 февральдә туган танылган шәхесләр
- **1956** – Алмас Нәзиров, элекке Татарстан урман хуҗалыгы министры (2014–2017), Россиянең һәм Татарстанның атказанган урманчысы;
- **1968** – Әнисә Сабир, Камал театры артисты (1988–2001).
- **1988** – Евгений Черемисин, Россия футболчысы.

Ә менә актриса, им-томчы Аграфена Васильева кәбисә елга да, төрле могҗизаларга да ышана. «Ышанмыйча мөмкин түгел. Әби-бабайлар безне, кәбисә елда өйләнешмәскә тырышыгыз, Ул хәвефле ел дип санала», – ди.

Сөйләшкән арада без аннан Яңа ел алдыннан теләк теләүнең үзенчәлекле ысулларын да сорадык. Аграфена ханым сүзләренчә, яңа ел муллыкта үтсен, кесәдә һәрвакыт акча булсын өчен, иске елда үзеңә почта аша акча салырга кирәк. «Аның сиңа яңа елда килеп җитүе мөһим. Чыршы бизәгәндә, теләгеңне инде чынга ашкан кебек итеп язып элүнең дә файдасы бар. Әйтик, «Мин үз фатирымда яшим», «Минем яхтам бар», «Фәлән төстәге машина алдым», «Улым яки кызым өйләнде». Нәрсә телисең, шуны язасың. Чыршыны сүткәндә, энергетика тәэсир итсен өчен, кәгазьләрне аерым бер урынга алып куярга кирәк», – дип сөйләде ул.

Йолдызлар шулай куша

Халык телендә кәбисә елга бәйле ышанулар арасында төрлесе бар. Бу елда теләк-хыялларны чит кешеләргә сөйләмәскә кирәк, кәгазьгә язып куйсаң, шул җитә, диләр. Туйны кичектереп торуың яхшырак. Аерылышырга да ярамый. Түзә алмасаң, сөлге сатып алып, гыйбадәтханәгә бирсәң, җайлана, имеш. Яшәү урынын да үзгәртмәү хәерле. Әгәр инде күченергә туры килсә, ишек өстенә дага ябыштырып куярга онытмаска кирәк. Малларны саткан очракта фәкыйрьлек килүе бар...

Асылда, дүрт елга бер мәртәбә 366 көн туры килүенең фәнни аңлатмасы бар. Җир шарына Кояш тирәли әйләнеп чыгу өчен 365 көн, 5 сәгать һәм 46 минут вакыт кирәк. Менә артык сәгатьләр дүрт ел эчендә бер тәүлек булып җыела. Шулай итеп, артык бер көн календарь елы белән астрономик ел тәңгәл килсен өчен өстәлә.

Кәбисә дә, аждаһа да

Беренче карашка, бик куркыныч ел көтелә кебек. Ләкин фараз-фикерләрнең кайсына ышанасың бит. Мәсәлән, белмәсәгез белегез: яшел аждаһа безгә 10 февральдә генә килеп җитәчәк. Аңа кадәр йомшак куян «патша»лыгында яшәп торачакбыз. Ай циклы буенча рәте шулай икән.

Аждаһа елыннан ниләр көтәргә соң? Мифик персонаж буларак, яшел аждаһа – көч, кыюлык, намус, уңыш, иҗат һәм лидерлык символы. Элек-электән аның ил-көнгә уңыш, үзгәрешләр һәм шул ук вакытта көтелмәгән хәлләр алып килүенә ышанганнар. Моннан тыш, үз елында туучыларны аждаһа ел дәвамында саклап йөртә, дигән ышану да бар.

Ә кәбисә белән аждаһа очрашса, ни була икән? Астролог Елизавета Алехнович сүзләренә караганда, елның кәбисә булуы вакыйгаларга берничек тә йогынты ясамаячак. «Елның киеренкелеге, барыннан да элек, планеталарның ничек хәрәкәт итүеннән тора», – ди ул. 2024 елга, планеталар һәм йолдызлар торышыннан чыгып, менә нинди фаразларын җиткерә:

– Киләсе елда нининдидер зур үзгәрешләр, вакыйгаларда кискен борылышлар булырга мөмкин. Киеренкелек сакланачак, әмма ул артык сизелмәячәк. Куплләргә 2024 ел тормышларын үзгәртергә мөмкинлек бирәчәк. Ләкин мөмкинлекне кулдан ычкындырмас өчен, уяу булырга, үзеңә дә тырышырга кирәк булачак.

Саннар телендә

Кәбисә елда өйләнешергә ярамый. Дүрт елга бер килә торган ел турындагы иң киң таралган ышану шушыдыр, мөгаен. Әмма бу гына Татарстанда яшәүчеләргә тигез гомер итәргә артык комачауламый булса кирәк. Һәрхәлдә, статистик мәгълүматлар шул хакта сөйли. Ел елга туры килми, әлбәттә. 366 көнлек кайбер елларда, башка чор белән чагыштырганда, өйләнешүчеләр кимрәк булып, аерылышучылар саны арткан. Кайвакыт – киресенчә. Республика өчен бик уңышлы еллар да бар. Әйтик, 2008 елда Татарстанда туучылар саны 13 елга беренче тапкыр рекорд куйган. Калганын үзегез дә түбәндәге таблица ярдәмендә чагыштырып карый аласыз.

Ел	Өйләнешүчеләр	Аерылышучылар	Туучылар
2020	19350	11353	41598
2016	25778	13450	56381
2012	33172	15457	56005
2008	29497	15670	44926

Лилия ГЫЙМАЗОВА
Сәрия МИФТАХОВА

Фикер

Алла ШАИНОВА, гаилә психологы:
– Фаразлар күп төрле. Ел, чыннан да, гади түгел. Ләкин, кагыйдә буларак, без нәрсәгә ышанабыз – шул тормышка аша. Һәр кеше үзенчә яшәргә тырыша. Иң мөһиме, эчке тоемлавыңа игътибар итәргә кирәк. Без нәрсәнең начар, нәрсәнең яхшы икәнен алдан тоемлый алабыз. Яңа елда күңел кушмаган урыннарга бармагыз. Шуны онытмагыз: безнең борчу-куркулар кем өчендер файдалы. Шуңа күрә фаразларны азрак тыңлагыз. Алар кәефне дә боза бит...

Рөстәм хәзрәт ЯСӘВИЕВ, «Рәхмәтулла» мәчете имам-хатыйбы:
– Безнең халыкта төрле ырымнар бар. Ә диндә алар берничек тә нигезләнмәгән. Хәтта дини кешеләрдән дә «Ике гает арасында өйләнергә ярамый» дигән фикерне ишетергә туры килә. Бу – гыйлемсезлектән. Халык телендә тузга язмаган фикерләр күп. Хәзер менә нумерология килеп чыкты, саннарга ышаналар. Кәбисә елдан куркучылар да бар. 2000 елда «дөнья бетә» дигән имеш-мимеш чыккан иде. Имеш, пәйгамбәребез с.г.в., ике бармагын янәшә куеп, «ике» дип күрсәткән. Хәдисләрдә бу, минем килүем белән кыямәт көне якынаячак, дигәнне аңлаткан. Асылда адәм баласының җыясы ризыгы алдан язып куелган. Көн саен, өйдән чыкканда, Аллаһка тапшырып чыгып китәргә кирәк.

РОССИЯ ТАРИХЫНДА
КӘБИСӘ ЕЛДА НИНДИ ВАКЫЙГАЛАР БУЛГАН?
- 2020 ел – коронавирус пандемиясе.
- 2012 ел – Владимир Путинның өченче тапкыр Россия Президенты итеп сайлануы (сүз уңаеннан, 2024 елда да Президент сайлаячакбыз).
- 2008 ел – «Евровидение» халыкара җыр бәйгесендә беренче һәм соңгы мәртәбә Россия җырчысы Дима Биланның җиңүе.
- 2004 ел – Грозныйдагы стадионда шартлауда Чечняның беренче Президенты Әхмәт Кадыйровның вафат булуы. Беслан мәктәбендәге теракт.
- 2000 ел – Мәскәү метросында теракт нәтиҗәсендә шартлау.
- 1980 ел – Мәскәүдә узган Олимпиада.
- 1924 ел – Владимир Ленинның үлгән елы.

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

УРЫН ТҮРДӘ

АЖДАҺА ЕЛЫНДА ТУГАННАР 2024 ЕЛДАН НӘРСӘ КӨТӘ?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Киләсе елның хуҗасы – яшел агач Аждаһа. Ут чәчеп торуы белән куркытса да, аның кешеләргә карата хәерхаһлы булуына да өметне өзмибез әле. Аждаһа елында дөньяга килүчеләргә дә бик әйбәт сыйфатлар өеп бирелә, ди. Әйтик, алар туры сүзле, сәләтле, акыллы, амбицияле, гадел була икән. «ВТ» хәбәрчесе Аждаһа елында туганнар белән аралашты, алдагы елдан ни өмет итүләрен белеште.

**Илсур ҺАДИУЛЛИН,
Татарстанның мәгариф һәм фән министры (1964 елгы):**
– Аждаһаның явыз булмаганы миндер ул. Шул явыз булмаганга күрә интегәм дә *(көлә)*. Әмма минем Аждаһа буласым килми дә. Гаделлекне яратам. Амбиция дигәннән, максатларга ирешергә яратучы кеше мин. Мөстәкыйльлекне дә яратам. Әгәр дә кешене читлеккә ябып яисә төрле яклап богаулап куялар икән, аның булган сәләтләре дә ачылмаска мөмкин. Максатларны тормышка ашыру өчен ирек һәм мөстәкыйльлек кирәк бит. Мөстәкыйль булу ул әле теләсә нәрсә уйлап, эшләп йөрү түгел. Принципларым бар. Читтән яхшырак күренәдер инде.

Безнең чорда Яңа ел бүләкләрен теккән капчыкларда бирәләр иде. Без инде мандарин, банан, әфлисун ашап үскән буын түгел. Минем яшьлек – сызык белән бәрәңге, коймак *(көлә)*. Истә калган тагын бер тәм-том бар икән әле, ул – билле прәннек.

Форсаттан файдаланып, Яңа ел белән барыгызны да котлыйм! 2024 елга теләгем шул: барыбыз да күбрәк газета-журналлар укыйк, саф һавада йөрик, туганнар белән аралашыйк! Аждаһа елын каршы алам дип, кешеләр аждаһага әйләнмәсен иде.

**Альберт РӘХМӘТУЛЛИН,
Кайбыч районы башлыгы (1976 елгы):**
– Җитәкче кеше усал була, дип сөйлиләр. Халык белән эшләгәч, туры булгач, янәсе. Мин андый кеше түгел. Табигатем белән бик йомшак мин. Кирәк чакта катылык күрсәтә алам, мондый сыйфат та юк түгел.

Аждаһа елы – безнең ел килә. Хәер, 2023 ел район тормышы өчен дә, шәхсән үзем өчен дә бик уңышлы булды. М12 трассасы ачылды. Киләсе елда тагын бер зур объектны – мегаферманы ачарга җыенабыз.

Балачакта Яңа ел иң көтеп алынган бәйрәм иде. Хәер, хәзер дә шулай бит ул. Әле районда узган Чыршы бәйрәмендә дә: «50 яшькә таба атласак та, Кыш бабайны, Кар кызын көтәбез. Ул да безгә берәр бүләк бирмәсме икән дип өметләнәбез», – дигән идем. Күңел могҗиза көтә инде ул. Балачакта безнең өчен барысы да бүләк иде инде. Купшы заманнар түгел бит. Нәрсәгә дә шатлана белдек.

Яңа елга иң зур теләк шул: махсус хәрби операциядәге егетләребез исәнсау туган якларына әйләнеп кайтсын иде. Моны һәркайсыбыз тели.

**Данис ШАКИРОВ,
Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе (1988 елгы):**
– Аллаһы Тәгалә киләчәк елыбызны хәрәкәттә, сау-сәламәт булып уздырырга насыйп итсен! Ил-җирләребезгә тынычлык килсен. Шулай ук күңел тынычлыгы булсын дип тә телим.

Уңай сыйфатларны һәркайсыбыз үзендә күрергә тели инде ул. Аждаһа елында туганнар мөстәкыйль, гадел, амбицияле, романтик була, диләр. Ихластан әйтәм: бу сыйфатлар миңа да хас. Мөстәкыйль булырга да тырышабыз, гаделлек тә сөябез, романтик рух та бар. Болар – көнкүрештә, тормыш иткәндә калкып чыга торган сыйфатлар. Татар җәмәгатьчелеге, гомумән, бөтен татар дөньясы белән төрле юнәлештә эш башкарганда да бу сыйфатлар бик кирәк. Алар миңа тәрбиядән сеңгән.

Һәр кешегә җылы мөнәсәбәт хөкем сөргән гаиләдә үскән кеше мин. Һәр Яңа елны бик көтеп ала идек. Әтием озак еллар дәвамында автовоз йөртте. Эш сәфәрләре күп булды, өйгә сирәк кайтып керде. Яңа елда гаиләбез тулысы белән җыела иде! Әтием күпләп бүләкләр алып кайта.

Яңа ел күңелгә шул бүләкләр белән кереп калган. Без бит аны ел буе көтеп ала идек. Туганнар белән очрашу, авылга кайту матур хатирәләр булып күңел түрендә саклана.

Адәм баласының психологиясе шулай корылган: нәрсә күрергә телисең, шуны күрәсең. Һәр күренештән матурлык, ихласлык күрәсең икән, ул шулай була да. Негатив эзләсәң, теге яисә бу күренештән начарлык табасың. Аждаһа белән дә шулай. Аннан усал образ ясамыйк. Мин аны могҗизага бәйләр идем. Киләчәк Аждаһа елы могҗизаларга бай булсын! Адәм баласы хыяллар белән яшәргә тиеш.

**Ирек ХАФИЗОВ,
Татарстанның атказанган артисты (1976 елгы):**
– Гаделлек тә, романтик рух та, мөстәкыйльлек тә – барысы да хас миңа. Бер карасаң, бу дөньяда гадел булмыйча яшәү җиңелрәктер дә әле. Аждаһа энергиясен сизәм. Үз елың килгәндә, сөенәсең инде. Хәзер инде без, нинди ел килсә дә, ил-көн тыныч булсын, дип телибез.

Без үскәндә Яңа елны көтеп ала идек. Чөнки әти-әниләр колхоздан бүләк алып кайта. Мандариннарны да шунда гына күрдек. Хәзер генә ул ел әйләнәсе төрле җиләк-җимеш сатып алырга мөмкин. Яңа ел күчтәнәчләрен матур итеп бизәлгән атлар җигеп, өйдән-өйгә таратып йөриләр иде. Бүләге, чынлап та, бик саллы була иде аның.

Кич исә авыл клубында бал-маскарад! Андагы ихласлыкны, күңеллелекне сез күз алдыгызга да китерә алмыйсыз! Анда бөтен авыл бии, җырлый, күңел ача, клуб халык белән шыгрым тулы. Артист булам дип хыялланмаган булсам да, клоун булып уйнап йөргәнем истә. Бик рәхәт вакытлар бу. Соңыннан лотерея уйнаталар. Иң зур бүләк – шампан шәрабе.

**Илүзә КАСЫЙМОВА,
«Татар радиосы» ди-джее (2000 елгы):**
– Аждаһага хас барлык сыйфатлар да туры килә безгә. Кәҗәмөгез буларак та әле! Без мөстәкыйль, барлык эшне үзебез башкарабыз, кемгәдер кушмыйбыз. Гаделлек яратам. Кыек эшләр күрәм икән, бу минем ачуымны чыгара.

Күпләр Кәҗәмөгезләрне коры, салкын дип саный. Әмма бу алай түгел! Без үз кешеләребез янында бөтенләй башка. Ачык күңелле, мәхәббәтле без. Мәсәлән, мин кочаклашырга яратам. Аждаһа ут чәчкән кебек, мин дә яндырып алырга оста. Гадәттә, сүз белән. Аждаһа сыман очарга яратам. Әмма – хыял дөньясында.

«Бәйрәм алдыннан йога белән шөгыльләнмим, дөрес тукланмыйм»

Тылсым тулы бәйрәм киче турында Кыш бабай белән Кар кызыннан да сорадык. 31 декабрьне ничек каршы алалар икән? Балалар аларга нәрсә әзерли? Нинди бүләкләр сорый?

:: Кыш бабай белән Кар кызының көне ничек үтә?

Кар кызы:
– Хәзерге вакытта безнең көннәребез бик тыгыз. Арыйбыз да. Шуңа күрә Яңа ел алдыннан бернәрсә дә әзерләмим. Берәр кая кереп ашыйбыз гына. Кыскача әйткәндә, Яңа ел җитәрәк мин йога белән дә шөгыльләнмим, дөрес итеп тукланмыйм да. Кыш бабай да шулай: спорт залына йөрми, балыкка бармый. Моңа көчебез калмый *(көлә)*. Балаларны котлап кайткач, киемнәребезне тәртипкә китерәбез, кирәк-яракларыбызның төзеклеген барлыйбыз.

:: Балалар сезне каршыларга ничек әзерләнә? Нинди бүләкләр тапшырасыз?

Кар кызы:
– Балалар безгә шигырьләр әзерли. Өч телдә дә сөйлиләр. Әйтик, инглиз, рус, татар телләрендә. Бик сирәк кенә биюләр дә әзерлиләр. Җырлар тагын да сирәгрәк.

Кыш бабай:
– Әле күптән түгел генә бер малай безне гитарада уйнап каршы алды. 2 яшьлек сабый брейк данс биюе күрсәтте. Безгә бик ошады.

:: Без гел Кыш бабайдан нидер сорарга күнеккән. Ә Кыш бабай үз теләкләрен кемгә җиткерә икән?

Кыш бабай:
– Язмышның үзенә. Хыяллар чынга ашсын өчен хыяллану гына җитми. Тырышлык та кирәк бит әле. Хыяллар ул – безнең эш-гамәлләребезнең нәтиҗәсе. Барысы да – үзебезнең кулда.

Гөлгенә
ШИҺАПОВА

РӘХМӘТ КҮПЕРЕ

ГАЗЕТА УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ЯРДӘМ ИТКӘН КЕШЕЛӘРНЕҢ ХӘЛЕ НИЧЕК?

Ел дәвамында нинди генә язмышлар белән очрашмадык. Газетага ярдәм сорап шалтыраткан, хатлар язган кешеләрнең берсе дә читтә калмады. Кемнәргәдер сез – укучыларыбыз белән бергә ярдәм иттек, ә кемнәрнеңдер борчулары редакциябез эчендә хәл ителде. Улы махсус хәрби операциядәге анага утын кайтарту, авырулар яшәгән урамга ут керттерү, бакча уртасында комачаулап торган баганаы алдырту, өй каршында үскән корыган агачны кистерү, инвалидларга тиешле ярдәм күрсәтү – болар башкаларга күрсәтү яки мактану түгел, ә ике арадагы күперне тагын да ныгыту өчен эшләнде. Бүгенге заманда андый күперләр һәркемгә кирәк.

«Мин бу көннәрне күрмәс идем»

Минзәлия: «Аллаһы Тәгаләдән әнием һәм сабыйларым хакына исән калуымны сорадым», – ди.

Казанда яшәүче Минзәлия Миңнебаева белән килеп чыккан куркыныч вакыйга турында бик күпләр белә. Сатучы булып эшләгән хатынны элеккеге ире пычак белән яралый.

– Элеккеге ирем балаларны үзенә алып торгалый иде. Ул көнне дә авылга алып китәсе килде. Мин каршы килмәдем, әмма бер кызыбыз, кайтмыйм, диде. Аны-моны уйламадым, эшкә киттем. Ә аннан үз аягымда кайтырга насыйп булмаган икән, – дип искә ала Минзәлия. – Умыртка баганасына һәм бөерләремә зыян килгән иде. 2 литрга якын каным аккан. 6 нчы хастаханәгә алып барганнарын хәтерлим. Әмма үземнең кыяфәтемне күргәч, аңымны югалтып егылганмын.

Табиблар, яшәмәс, дисә дә, аякка басар көч таба алды Минзәлия. Өч баласы, газиз әнисе хакына савыкты ул. Без бу хакта ишетүгә үк, Минзәлиянең балалары белем алган мәктәп директоры белән элемтәгә кереп, алар гаиләсенә ярдәм оештырдык. Табиблар аңа III группа инвалидлык бирә. Ул таякка таянган килеш эшкә чыгарга мәҗбүр була. Гаиләсен кайгыртасы бар бит.

– Умырткалыгым әле дә сызлап интектерә. Нерв җепселләре күчереп утыртсаң, ныклап йөрер идең, дигәннәр иде. Инде хәзер ташламалар юк, барлык анализлар түләүле. Мине Волгоград шәһәрендә урнашкан тернәкләндерү үзәгенә җибәрделәр. Әлегә шунда дәваланам. Алга китеш күренмәсә дә, күңелдә өмет бар. Кыйммәтле уколларны бушка салалар. Улым тугызынчы сыйныфтан соң көллияткә керде. Әкрен генә укып йөри. Кызларым да, тырышып, чирек ябалар.

Минзәлия Яңа елга өенә кайтмакчы. Сабыйларын бик сагынган. Газета аша мәрхәмәтле кешеләргә әйтер сүзе дә бар.

– Сез булмасагыз, бу көннәрне күрмәс идем. Кем генә булышмады. Каян гына акча салмадылар. Шөкер, фатир өчен бурычларым калмады, ипотекамны яптым. Тормышымның иң авыр чагында миңа булышкан һәр кешегә рәхмәтемне җиткерәм, – ди ул. – Мин хәзер һәр туган таңга сөенеп яшим. Исән калуым белән бәхетлемен. Балаларым хакына аякларымда ныклап йөрсәм иде дип телим. Бар кешегә дә гаиләсендә тынычлык, нык сәламәтлек насыйп булсын.

«Сез язгач, акча җыелды»



Дамирның әнисе Розалия һәр гаиләгә иминлек һәм барлык сабыйларга сәламәтлек тели.

Биектау районының Усад авылында гомер итүче Розалиянең улы Дамир җитлекмичә туа. Баштарак бер кимчелеген дә күрмәсәләр, соңрак акылга зәгыйфь икәнлеге ачыклана. Алар улларын кая гына йөртми. Табиблар ялгышкандыр дип тә өметләнәләр. Тик анализ нәтиҗәләре авыруның барлыгын раслый. Ир белән хатынга язмышлары белән килешергә кала. Дамирның авыруын тизрәк ачыклап, дөрес дәвалану аласы килә аларның. Әмма генетик анализлар тапшыру өчен зур суммада акча кирәк була. Розалия, ярдәм сорап, безгә мөрәҗәгать иткәч, аның язмышы турында газетада яздык.

Күп тә үтмәде, аннан җылы сүзләр белән тулы хат килеп төште.

– Улым Дамирның язмышын «Ватаным Татарстан» газетасына язып чыккач, безгә ярдәм итүчеләр күп булды. Мин анда балама кыйммәтле операция кирәклеген дә әйткән идем. Уйламаганда бер белмәгән кешеләрнең безгә ярдәм итүенә бик сөендем. Безгә бик күп кешеләр акча күчерде. Барлык гаиләбез белән бик куандык һәм барлык кешеләргә чиксез рәхмәтлебез, – дигән Розалия.

«Чит кешеләр ташламады»

Венераны коткара алмасак та, әнисе Марина апа белән элемтәне өзмибез.

Кореяга эшкә китеп, бәлагә тарыган Мамадыш районының Владимир авылы кызы Венера Сапурина турында гел язып тордык. 27 яшьлек кызның әнисе Марина ханымның, баламны туган якка кайтарырга булышсагыз иде, дип ялваруын ишеткәч, битараф калмадык. Бөтен республика белән акча җыйдык, җитәкчеләргә дә хәбәр салдык. Венераның бар анализлары яхшырып китүен, тизрәк кайтуын көттек. Кайтарыр өчен хәтта очкыч та табылды. Юлга чыгар өчен анализ нәтиҗәсе кирәк иде. Ул әзер булырга бер көн кала Венера вафат булды. Кызга туган ягына исән килеш кайтырга насыйп булмаган икән.

«ВТ» журналисты Сапуриннар гаиләсенең авыр хәсрәтен уртаклашып, кызны соңгы юлга озатырга да кайтты. Баласын югалткан ата-ананың, кызның якыннарының ничек өзгәләнүен күрергә туры килде аңа. Кызын алып кайтырга дип, үзе дә чит илгә чыгып киткән, 4 ай буе өзгәләнеп яхшы хәбәр көткән, ахырга кадәр өметен өзмәгән Марина ханым көчле рухлы булып калырга тырыша. Ул сыңарларны күтәрергә, әле улының сабыйларын үстерешергә, аларга терәк булырга сүз бирде.

– Күңелемдә бер генә теләк: мин кичергәннәрне бер анага да күрергә язмасын! Вакыт – дәва, диләр. Юк. Торган саен күңелем айкала. Үзем үлгәнче онытa алмаслык ярам бу, – ди Марина ханым. – Гаиләбез өчен авыр ел булды. Кая барып бәрелергә белмәгәндә, «ВТ» редакциясе безгә ярдәм итте. Хәсрәтемне үзегезнеке итеп, язып чыктыгыз. Газета аша безгә ярдәм иткән һәркемгә рәхмәтемне җиткерәм. Ачы хәсрәтләр күрмәгез!

«Буш вакыт табармын!»

«Ватаным Татарстан» газетасында эшләвемне белгәч, Казанның 182 нче мәктәбендә укучы 12 яшьлек Әминә Фәрхетдинова Кыш бабайга җиткергән хыялын әйткән иде. «Җырчы Илнат Фәрхуллинның иҗатын яратам. Сеңлем Мәрьям белән аны күрәсебез килә», – диде ул. Икенче көнне үк җырчыга шалтыраттым. Илнат берсүзсез ризалашты. Узган шимбәдә кызлар яраткан җырчылары белән очрашты.

Илнат абыйлары очрашуга бүләкләр белән килгән. Кызларны сөендереп кенә калмады, аларны тәм-томнар белән сыйлады да. Рәхәтләнеп сөйләшеп утырды. Ничек укуларын, нәрсә белән шөгыльләнүләрен дә сорады. Җырчы егет концертына чакыргач, балаларның сөенече тагын да артты.

– Балаларны бик яратам. Үземнең кызыма да – 12 яшь. Сабыйлар хыялланырга һәм теләкләренең чынга ашуын күрергә тиеш. Җырларымны яратып тыңлаган, башкарган кызларга рәхмәт. Әле менә Әминә белән бергә концертымда берәр җыр да башкарырмын, – диде ул.

Әминә яраткан җырчысы Илнат Фәрхуллин белән бер сәхнәдә җырлаячак.

2023 ел вакыйгаларга бай булды. Ниһаять, Камал театрының яңа бинасы төзелеше башланды. Казан Кремленең Спас манарасы төзекләндерелеп, мультимедиалы музей эшли башлады. Җәмигъ мәчетнең урыны тәгаенләнде. Татарстан районнары, шәһәрләре исә мәдәни башкала исемен алу өчен көрәште. Нәтиҗәдә Арча барыннан да мәдәнирәк булып чыкты. Әдәбият, театр, кино, эстрадада нинди уңышларга ирешелгән? Бу сорауга белгечләр белән бергәләп җавап эзләдек.

Мәдәни нәтиҗә

2023 елның иң истә калган әдәби, театраль, эстрада вакыйгалары, фильмнары

Әдәбият

Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары **Илсөяр Ихсанова** фикеренчә, төп әдәби казаныш – төрки әдәбиятларның бер-берсенә якынаюы:

– Тел комиссиясе ярдәме белән яңа исемнәр табу эше дәвам итә. Әдәби бәйгенең быелгысын мин хәтта ел вакыйгасы дип бәяләр идем. Ник дигәндә, бер ел дәвамында 23 роман язылган һәм тәкъдим ителгән бит! Димәк, ул иҗат әһелләрен уяткан. Китаплар мәсьәләсенә килгәндә, миңа татар китабының башка телләргә тәрҗемә ителүе, дөньяга чыгуы әһәмиятле. Бу җәһәттән, Нурихан Фәттахның «Сызгыра торган уклар» романы төрек теленә тәрҗемә ителүен әйтеп үтәргә кирәк. Берлектә «Язучы» нәшрияты эшли башлады. Бу да – безнең өчен вакыйга. Аңа ихтыяҗ, тәрҗемә үзеге эшли башлагач, бермә-бер артты. Агымдагы елда төрки әдәбиятлар бер-берсенә тагын да якынайды. Әйтик, төрки дөнья язучыларының Әнкарада узган корылтаенда, төрле форумнарда татар әдипләре дә катнашты. Быелның төп әдәби вакыйгасы Төрки әдәбият фестивале була алыр иде. Әмма ул киләсе елның маена чигерелде. Язучылар берлегенең 90 еллыгы белән бергә ул киләсе елның матур бер вакыйгасына әверелер.

Сүз уңаеннан, Татарстан китап нәшрияты быел иң күп сатылган китаплар исемлеген тәкъдим итте. Иң күп сатылганнар арасында – классик язучыларның кабат бастырылган китаплары. Бу бер яктан сөендерә, икенче яктан уйландыра, билгеле.

ПРОЗА

1. **Нәбирә Гыйматдинова.** «Онытмадым».
2. **Габдрахман Әпсәләмов.** «Ак чәчәкләр».
3. **Фәнис Яруллин.** «Кайту».
4. **Зөлфәт Хәким.** «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?»
5. **Айгөл Әхмәтгалиева.** «Туташ».

ПОЭЗИЯ

1. **Роберт Миңнуллин.** «Мәхәббәтле күзләрем».
2. **Габдулла Тукай.** «Сайланма әсәрләр».
3. **Муса Җәлил.** «Моабит дәфтәрләре».
4. **Фәнис Яруллин.** «Давыл оясы».
5. **Хәсән Туфан.** «Каеннар сары иде».

БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ

1. **Абдулла Алиш.** Әкиятләр.
2. **Чулпан Харисова, Фираз Харисов.** Иллюстратив сүзлек.
3. **Габдулла Тукай.** «Шүрәле», «Су анасы».
4. **Татар халык әкиятләре.**
5. **Дидактик карточкалар (алфавит).**

Театр

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче **Әлфәт Закирҗанов** әйтүенчә, театр дөньясында да яңалыклар бар:

– Татарның 13 театры да уңышлы гына эшләп килә һәм быел да алар берничә премьера белән сөендерде. Камал театрының «Болганчык еллар» (Мәхмүт Галәү, реж. – Фәрит Бикчәнтәев), «Күзге кайтаваз» (Рөстәм Галиуллин, реж. – Фәрит Бикчәнтәев), «Ситса туй» (Илгиз Зәйни, реж. – Айдар Җаббаров), «Игезәк» (Ркаил Зәйдулла, реж. – Фәрит Бикчәнтәев) кебек спектакльләре тулаем алганда күңелдә канәгатьлек хисе калдырды. Бу театр тамашачының төрле булуын исәпкә алып эшләвен дәвам итә, әйдәп баручы театр вазыйфасын башкара. Шулай да, Камал театрының күңелемдә калган премьерасы «Игезәк» булды. Бу – тарихи әсәрне заманча куюның бер матур үрнәге.

Тинчурин театры да төрле жанрдагы спектакльләр тәкъдим итте: «Яратам! Бетте-китте!» (Ләйсән Эминова, реж. – Зөфәр Харисов), «Җилкәнсезләр» (Кәрим Тинчурин, реж. – Туфан Имаметдинов), «Идегәй» (реж. – Туфан Имаметдинов). Алар арасында «Идегәй» шактый бәхәсле булды. Мин ул фикерләрнең күбесе белән килешәм, кайсыларын кабул итеп тә бетерә алмыйм. Тулаем алганда, кызыклы, бәхәсле спектакль, андыйлар да булырга тиеш дип саныйм. Алар арасында иң көчле постановка – «Җилкәнсезләр». Бу хакта аерым да билгеләп үтәрмен әле.

Кариев театры «Җырлап яшик» (Рәмис Латыйпов, реж. – Ренат Әюпов), «Әлифба» (реж. – Лилия Әхмәтгалиева), «Ал җилкәннәр» (реж. – Ренат Әюпов) спектакльләре белән сөендерде. Алар арасында иң яхшылары дип «Әлифба»ны һәм «Ал җилкәннәр»не атар идем.

Әлмәт театрында «Ат карагы» (Туфан Миңнуллин, режиссеры – Айдар Җаббаров) бәхәсле спектакль булды. Әмма мин режиссер эзләнүләрен кабул иттем, Туфан абый фикерләре заманча үстерелгән дигән бәя бирдем.

ЕЛ ВАКЫЙГАСЫ БУЛЫРЛЫК СПЕКТАКЛЬ – «Җилкәнсезләр».

Куелу форматы, оста режиссура, тамашачыны шул заманга күчерүе, вакыйгаларда катнашып утыру мөмкинлеге тудыруы белән отышлы.

Кино

Россия кинематографистларының Татарстан бүлеге җитәкчесе **Илдар Ягъфәров** елның төп картиналарын һәм проблемаларны атады:

– Бер караганда әллә ни үзгәреш тә юк кебек, ә икенче яктан ниндидер зур хәрәкәт башланганы шәйләнә. Яшь егетләр – Илшат Рәхимбай, Байбулат Батулла бик яхшы фильмнар төшерделәр. Безнең картина да («Исәнмесез?» – **Ред.**) үзен күрсәтә алды. Тамчы ташны тишкән кебек, тамчылап җыелган картиналар ниндидер бер зур нәтиҗәгә китерер. Чөнки шундый бай, зур, күәтле татар мәдәнияте кинематографсыз була алмый, бары тик вакыт кына кирәк. Миңа «Пыяла» җыры астында талантлы рус актерларының уйнавы да ошый. Бу да безнең кинематографка этәргеч бирәчәк. Карагыз сез, әлеге картинада нинди шәп актер – Рүзил Миңнекаев барлыкка килде. Ул бит иң шәп артистлар белән бер дәрәҗәдә уйнады! Бу безгә файдага гына.

Безгә бөтен юнәлештә үсәргә кирәк. Сериаллар да булсын, татар классиклары әсәрләрен экраннан күрсәтү дә – барысы да кирәк. Җыеп әйткәндә, процесс бара. Әмма мин һәрчак системалы эш яклы. Әлегә система юк, Кино фонды да юк. Ә чын талант ул үҗәт түгел, андыйларга системалы эш булганда гына ярдәм итеп була. Башкортстанда, мәсәлән, Кино фонды бар. Аңа елына 50 миллион сум акча бүлеп бирелә. Менә хәзер анда фонд хисабына елына икешәр картина әлгертәләр. Якутиянең дә кино фонды бар. Анда 70 миллион сум бүлеп бирелә. Татарстан өчен дә бу – хәлдән килерлек эш. Аннан бездә дә системалы рәвештә профессиональ фильмнар төшерелә башлар иде.

2023 ЕЛНЫҢ ТӨП ӨЧ ФИЛЬМЫ

«Ядәч. Истә!» (режиссеры – Байбулат Батулла).
«Микулай» (режиссеры – Илшат Рәхимбай).
«Без – 41 нче ел балалары» (режиссеры – Әмир Галиәскәров).

Эстрада

Татарстанның халык артисты, композитор **Зөфәр Хәйретдинов**, эстрадада ел артисты булырлык җырчылар бар, дигән фикердә:

– Татар эстрадасында быел бар да тыныч. Фестиваль, премияләргә кагылмыйча, шәхси концертларга күзәтү ясыйк. Чөнки безне грандиоз дип ышандырырга тырышкан «Үзгәреш җиле» дә сүнде. Ул баштан ук ыштансыз билгә каеш дәрәҗәсендә генә кирәк иде. Шуңа күрә яңалыкларны артистлар үзләре барлыкка китерергә тырышты. Шул ук вакытта кара пиар белән генә тамашачыны җәлеп итеп булмаганын да аңладылар бугай. Зур бәхәсләр, гаугалар чыкмады. Истә калырлык җырлар да булмады. Шуңа күрә артистлар элеккеге җырларга ябырылдылар. Әйтик, минем «Су буенда учак яна» җырын элек Зөһрә Шәрифуллина гына җырлый иде, хәзер кем генә алмаган аны. Бу бер яктан яхшы, икенче яктан артистның үзенә начар булырга мөмкин. Элек куелган планканы тота алмаса, аңа ретро җырлардан бер файда юк.

Елның иң шәп концерты – **Филүс Каһировн**ныкы.
Ел җырчысы һәм иң шәп шоу-программа иясе – **Илсөя Бәдретдинова.**

Гөлинә ГЫЙМАДОВА

< Ахыры. Башы 8, 22 декабрь саннарында

Кыз аңа текәлде. Бер мизгелгә салкын күзләрендә кешелеклелек очкыны ялтырап үтте сыман. Гүя бу олы яшьтәге абзыйны күргәч, үзенең ниндидер якын кешесен исенә төшерде. Кызганып та куйды шикелле, тавышы үзгәрде, җылылык бөркелгән төсле булды.

– Шәхси мәсьәләләр белән гадәттә сишәмбе көнне кабул итәләр...

Сәркатип кыз бу сүзләрне әйтү белән, Миңнулланың янәдән өстеннән тау төште сыман. Димәк, бүген дә үлеме кичектереләчәк. Ул, гафу сүзләрен мыгырдап, ишек тоткасына үрелде, әмма кыз әле үз сүзен әйтеп бетермәгән икән:

– Әмма безнең Данил Мансурович андый формальлекне яратмый. Диванга утырып торыгыз, хәзер мин аңа әйтәм. Фамилиягез ничек дидегез әле? Садриев? Яхшы.

Сәркатип, аны кабул итү бүлмәсендә ялгызын калдырып, имән ишек артына кереп югалды, икенче мизгелдә чыгып та җитте.

– Данил Мансурович сезне көтә.

Миңнулла түрә кабинетына атлады. Өстәл артыннан нәчәлнегә күтәрелде – киң җилкәле, озын буйлы, чәчен кыска гына кыркыткан егет иде ул. Каршы килеп, кул биреп исәнләште дә Миңнуллага утырырга тәкъдим итте, үзе каршысында урын алды.

– Гафу итегез, мин юридик затлар белән эшләү бүлегеннән... Садриев...

– Миңнулла Сәлимуллович, сезнең кемлегегез миңа мәгълүм, – диде нәчәлнеге. – Ни йомыш? Дикъкать белән тыңлыйм.

– Сүзне нәрсәдән дә башларга белмим, Данил Мансурович...

– Турыдан әйтегез. Тартынмагыз. – Җитәкченең тавышы көр, анда бер генә тамчы усаллык та, мыскыллау да тоелмады. Миңнуллага уңайсыз булып китте.

– Аңлыйсызмы, тормыш шактый катлаулы... Бу дөнья, үзегез беләсез, акчага корылган. Менә без карчык белән өч бүлмәле фатирда яшәп ятабыз. Икегезгә нәрсәгә өч бүлмә диярсез, билгеле. Ләкин безнең инде кая да булса күченеп, кечерәк метражга алмаштырып йөрергә хәлебез дә, кузгалырга теләгебез дә юк... Кыш көне шул фатир өчен 7–8 мең түләргә туры килә. Акча җитми инде ул, аны сез миннән яхшырак беләсез...

ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВ

ӨЯНӘК

(ХИКӘЯ)

Анда-монда бәргәләнеп, керделечыктылы нотык тота башлагач та, ул әледәнәле нәчәлнегенә куркулы карашлар ташлап алгалады. Тегесе башта кызыксынды кебек, аннан соң битараф халәткә күчте, ә хәзер ачуы кабара төсле тоелды.

– Беләм, Миңнулла Сәлимуллович, бик яхшы беләм. Ни кызганыч, хәзер түләнгән кадәресеннән артык хезмәт хакы түли алмыйм. Сезгә мәгълүм ки, бездә тариф сеткасы.

– Юк, мин хезмәт хакын арттыруны сорамыйм! – Һәм Миңнулла бер сулышта үзенең үтенечен әйтеп тә салды.

Данил Мансурович капылт кына урыннан торды, өстәле янына барып, бер бит кәгазь белән каләм алып килеп, Миңнуллага сузды.

– Ник сүзне шуннан башламадыгыз?! Әлбәттә, анысын гына эшлибез!

– Ә бер айдан соң...

– Вәгъдә бирәм – бер айдан соң сезне кире эшкә алабыз. – Җитәкче инде тө-

– Бу айда сезнең бүлек буенча өч мөһим отчет тапшырырга кирәк. Сездә ике вакансия буш тора, кеше таба алмыйбыз, беләсез инде. Әгәр шул отчетлар буенча ярдәм итсәгез...

– Эшлим, Данил Мансурович, эшлим! – Җитәкчеләренең ул башкарган эшнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеген белүе Миңнуллага чиксез горурлык хисе өстәде. – Мин ай буе көн дә гадәттәгечә эшкә йөрергә ниятлим!

– Аның өчен түли алмыйбыз...

– Сез нәрсә, нинди түләү! Мин болай гына, рөхсәт кенә булсын!

– Рөхсәт, әлбәттә...

Кайткач та, ул башта Фәнүсәгә, аннан соң, җае чыгып очрашкач, Сәлимгә җитәкче белән әлеге очрашу хакында бәйнә-бәйнә сөйләде, Данил Мансуровичны әле алай, әле болай мактады. Яшь кенә булса да, бөтен кешене дә белеп тора, аеруча Миңнулла кебек озак еллар эшләгән ветераннарны! Ул яса-

репкәгә үрелеп, кадрлар бүлегенә Садриев турында күрсәтмәләр бирергә керешкән иде.

Миңнулла калтыранган куллары белән эштән китү турында гариза язды. Аның үз гомерендә шушындый эчтәлекле беренче гариза иде бу.

Инде эш бетереп, кабинеттан чыгып китим дигәндә, ишектә аны Данил Мансурович тавышы туктатты:

– Миңнулла Сәлимуллович, бер генә үтенечем бар.

– Тыңлыйм сезне...

ган отчетларның мөһимлегеннән дә хәбәрдар! Күңеленә хуш килгән тагын бер нәрсә – бу ай дәвамында элеккечә үк эшкә йөрергә рөхсәт итүе. Димәк, аның урынына беркемне дә алмаслар!

Барысы да ул теләгәнчә килеп чыкты. Бер айдан соң аны кире эшкә алдылар. Аңа кадәр пенсия фонды белән бөтен формальлекләрне ерып чыкты.

Тик йокысы гына элекке халәтенә кайтмады. Тамагыннан ризык та һаман да рәтләп-юньләп үтмәде. Әллә моңа кадәр кичерелгән бимазаланулар үзенекен итте, әллә инде үзенең шулкадәр кадерле, эш өчен кирәкле кеше икәнлеген аңлаудан шатлыгы чиксез иде – йөрәге кагудан һич туктамады.

...Яңа шартлар буенча исәпләнгән пенсиясен банк аның кәртечкәсенә күчергәндә, Миңнулла абзый өендә иде. Телефонына хәбәр килүен белдереп, кыңгырау чыңлап куйды. Миңнулла калтыранган куллары белән телефонын алды. Ул инде яңа пенсиясенең нинди күләмдә булуын белә. Хәзер шуны раслаган хәбәрне генә укый да тәмам тынычланачак.

Хәбәргә басты. Экранда аңа нәкъ ул көткән күләмдә пенсия җибәргәннәре акка кара белән язылган иде. Элеккегедән нәкъ җиде мең сумга күбрәк. Дәүләт аны шулкадәр олылаган! Уйлап карасаң, кем инде ул шуның хәтле?! Ил өчен нинди батырлыклар кылган?! Шаккатмалы ачышлар да ясамаган, корал тотып, дошманнан да сакламаган. Иртән торып эшкә барып, кичтән өенә кайтып егылган гади бер хисапчы гына! Әмма ул да әнә нинди хөрмәткә лаек бит!

Кинәт тамагы кипте. Йөрәге тагын да ныграк кага башлады. Миңнулла тыны кысылуын, буыннарының хәле китүен тойды. Телефоны кулыннан төшеп китте.

– Фәнүсә, – дип пышылдый алды ул.
– Фәнүсә, «скорый» чакырт...

КОТЛЫЙБЫЗ!

Югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе, нәтиҗәле фәнни хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Казан дәүләт медицина университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры **Созинов** Алексей Станиславович, актив гражданлык позициясе, дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек идарәсе мәгариф программалары һәм проектлары бүлеге баш киңәшчесе **Хәмзин** Нияз Хәтмулла улы, илебез очкычлар төзү тармагын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы хезмәткәрләре: беренче бүлекнең өлкән инспекторы **Емелина** Елена Рудольфовна, 96 номерлы склад хуҗалыгы цехының склад мөдире Зәйнуллина Хавия Рафхат кызы, гальваник өслекләр цехы гальванигы **Зуйкова** Әлфия Гыйльметдин кызы, хәрби билгеләнештәге авиация техникасына техник контроль бүлегенең сыйфат буенча инженеры **Косенков** Николай Владимирович, программалар ярдәмендә идарә итү бүлеге инженер-программисты **Сюсина** Ирина Михайловна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Намуслы хезмәте, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыруга лаеклы өлеш кертүе өчен Казан шәһәр Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсе җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлеге баш белгече **Исламова** Лилия Салихҗан кызы **«Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия өзлексез һөнәри белем бирү медицина академиясе» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе филиалы – Казан дәүләт медицина академиясе ортопедия стоматологиясе һәм гомуми практика стоматологиясе кафедрасы доценты **Әмирханов** Минхарис Талип улына, «Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең наркология кабинеты табибы – психиатры-наркологы **Голубев** Вячеслав Сергеевичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең изоляция-диагностика бүлекчәсе мөдире, табиб-педиатры **Зыятдинова** Лилия Мәсгут кызына, «2 номерлы стоматология поликлиникасы» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе табибы – стоматолог-терапевты (Чаллы шәһәре) **Сафиуллин** Рафаэль Сабирҗан улына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Лицензияләү идарәсенең медицина эшчәнлеген лицензияләү бүлеге башлыгы **Байбикова** Лилия Ренат кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе операция шәфкать туташы **Волостнова** Наилә Марат кызына, Россия Федерациясе Хезмәт һәм халыкны социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Медицина-социаль экспертиза баш бюросы» федераль казна учреждениесенең 15 номерлы бюросы җитәкчесе – медицина-социаль экспертизасы табибы **Потапова** Лариса Геннадьевнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш шәфкать туташы **Трусова** Елена Владимировнага, «Нурлат үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе хирургия бүлекчәсенең палата шәфкать туташы **Хәйретдинова** Лилия Чыңгыз кызына **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Казаньсельмаш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең сатып алулар буенча директоры **Богданов** Вадим Артуровичка, «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы 34 цехы мастеры **Галиева** Дания Нәзыйф кызына, «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы баш механигы производствосының слесаре-ремонтчысы **Галимов** Кандел Кәшфел улына, «Зеленодольскиның А.М. Горький исемендәге заводы» акционер җәмгыяте генераль директоры **Филиппов** Александр Николаевичка, «Буа машина төзү заводы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры **Фомин** Олег Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ПАРСЕК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең архитектура бюросы җитәкчесе **Гыйниятов** Илдар Идегәй улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«ТЭКОРЕСУРС» махсуслаштырылган торак төзүче оешма җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Буа районы буенча бүлеге полиция участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлегенең полиция участок уполномоченные, полиция кече лейтенанты **Абделмәнов** Алмаз Әмир улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Идел буе федераль округы буенча Транспортта идарәсе Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Транспортта Казан линия идарәсе дежур часте оператив дежурные, полиция лейтенанты **Гыйззәтуллин** Марат Нурулла улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының наркотиклар әйләнешен контрольдә тоту идарәсе «Гром» махсус билгеләнештәге отрядының 3 нче хәрби бүлекчәсе өлкән оперуполномоченные (шартлаткычларны зарарсызландыру буенча техникы), полиция капитаны **Катков** Никита Евгеньевичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Алабуга районы буенча бүлеге штаб башлыгы, эчке хезмәт подполковнигы **Косолапов** Сергей Алексеевичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Түбән Кама районы буенча идарәсе җинаятьчеләрне эзләү бүлегенең шәхси милеккә каршы җинаятьләрне ачу бүлекчәсе оперуполномоченные, полиция капитаны **Никитин** Евгений Александровичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Идел буе федераль округы буенча Транспортта идарәсе Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Транспортта Казан линия идарәсе полиция патруль-пост хезмәте аерым ротасы 1 взводы 1 бүлекчәсе полицейские, полиция өлкән прапорщигы **Нуруллин** Ирек Фәрит улына, Татарстан Республикасы прокуратурасының федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек идарәсе икътисад өлкәсендә законнарның үтәлешенә күзәтчелек бүлеге өлкән прокуроры **Шакирова** Зөлфия Миңнегәрәй кызына, Татарстан Республикасы Рәисенең Эксперт департаменты җир-мөлкәт мөнәсәбәтләрен координацияләү һәм үстерү бүлеге баш киңәшчесе **Джавбураев** Әнвәр Равил улына, **«Юллар һәм Күперләр» акционер җәмгыяте коллективына, «Мостострой-11» акционер җәмгыяте коллективына, «Волгадорстрой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына, «РусРемСтрой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына, «Автодор» төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына, «Трансстроймеханизация» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына,** «Сервистехномонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзү эшләре җитәкчесе **Епишин** Сергей Владимировичка, «СтройМонтаж-Инжиниринг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең чуен һәм тимер-бетон конструкцияләрне монтажлау буенча монтажчысы **Калачев** Сергей Евгеньевичка, «7 номерлы төзелеш-монтажлау идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 4 номерлы төзелеш-монтажлау идарәсе баш инженеры урынбасары **Тизяев** Владимир Алексеевичка, «7 номерлы төзелеш-монтажлау идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 3 номерлы төзелеш-монтажлау идарәсе технологик җайланмаларны төзекләндерү буенча слесаре **Шаванов** Фёдор Николаевичка, «Әлмәт дәүләт нефть институты» дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең беренче проректоры ярдәмчесе, нефть һәм газ җиһазлары һәм машина төзелеше технологияләре кафедрасы өлкән укытучысы **Гыйлаҗева** Светлана Ришат кызына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның капиталь төзелеш идарәсе башлыгының җитештерү булмаган төзелеш буенча урынбасары **Закиров** Шамил Камил улына, **«Күперләр һәм Тоннельләр проектлаштыру» акционер җәмгыяте коллективына, «Бердәм оператор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына, «Зенит» волейбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешмасы (Казан шәһәре) коллективына,** Татарстан Республикасы Премьер-министры ярдәмчесе **Хәмәдишин** Дәүфит Закир улына, **ТАИФ компанияләр төркеме коллективына, «КАМАЗ» гавами акционер җәмгыяте коллективына, «СИБУР Холдинг» гавами акционер җәмгыяте коллективына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте коллективына Татарстан Республикасы Рәисенең Рәхмәте** белдерелде.

* * *

Балалар тәрбияләүдәге һәм гаилә традицияләрен ныгытудагы казанышлары өчен Казан шәһәренең Идел буе районыннан җиде бала анасы (аларның бишесе өч яшькә җиткән) **Семенова** Алла Олеговна **Татарстан Республикасының «Ана даны – Материнская слава» медале** белән бүләкләнде.

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

П2435 >>
571 сум 98 тиен
(җомга)
П2409 >>
1255 сум 86 тиен
(сиш., чәрш., җомга)

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040

info@vatantat.ru

420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

Беләсең килсә...

1 Россия тимер юлларында рельслар арасы ничә миллиметр?
а) 1520;
б) 1630;
в) 1680.

2 Классик бокс ничә раундтан тора?
а) 12;
б) 14;
в) 15.

3 «Мөгаллим Сәни» китабын кем язган?
а) Әхмәт Садри;
б) Садри Максуди;
в) Һади Максуди.

4 Дальнереченск шәһәренең 1972 елга кадәрге атамасы?
а) Дин;
б) Ислам;
в) Иман.

Җаваплар: 1. а); 2. а); 3. в); 4. в).



Әз-мәз мәзәк

– Уңышлы өйләнү нәрсә ул?
– Агулы еланнар тулы капчыкка кулың белән кереп, тузбаш чыгару.

***

– Кызык кеше сез. Эшне онлайн гына эшлисез, ә Яңа ел корпоративына офлайн киләсез.

***

Әгәр дә хатын-кыз хайваннар ярата икән, димәк, бик күп ирләрнең шанслары бар.

***

Быел бәйрәм чыршысы астында яңа фатир тапсаң иде!

***

Ничек шулай ул? 40 литрлы суны көчкә күтәрәсең, ә 50 килолы хатын-кызны күтәрү җип-җиңел.

***

– Син төнлә мине кабат Айгөл дип атадың!
– Караңгы иде бит.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: куәт, урама, инеш, сәфәр, Наил, көн, Лик, ым, Әнкәй, Шамов, но, мәми, йа, ас, Бабкина, ут, чек, еш, ыру, Лия, Данир, пас, Ален, песнәк.
Вертикаль: Кисекбаш, аучы, Амстердам, Әлфинә, мә, куас, ромб, ир, ВИА, ике, ун, РЕН, Найк, АН, ашамлык, АИГЕЛ, лә, имән, ширек, айлык, йозак.

Газетаның киләсе саны 5 гыйнварда чыга.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13596 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 372

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+